МИНИСТЕРСТВО
СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ
ҺӘМ АЗЫК-ТОЛЕК
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.08.2015 г.Казань № 194/2-пр

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2015 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Россия кредит оешмаларында алынган кредитлар буенча һәм авыл хуҗалыгына кагылышлы кредит бирә торган кулланучылар кооиеративларында алынган заемнар буенча процентлар түләү чыгымнарының бер өлешен каплау очен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында” 2012 елның 28 декабрендәге 1460 номерлы карарын үтәү максатында

**б о е р ы к б и р ә м:**

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-толек министрлыгының “2015 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме очен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Боерыкка 7 нче кушымтаны әлеге Боерыкка 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

1.2. Боерыкка 8 нче кушымтаны әлеге Боерыкка 2 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

1.3. Боерыкка 9 нчы кушымтаны әлеге Боерыкка 3 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасарлары Н.Л. Титовка йокләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

076006

2015 елның 17.08 194/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгына
1 нче кушымта

2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгына
7 нче кушымта

# Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан тыш), оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперацияләренә 2009 – 2015 елларда 1 елга кадәрге срокка Россия кредит оешмаларында алынган кредитлар буенча һәм авыл хуҗалыгына кагылышлы кредит бирә торган кулланучылар кооперативларында алынган заемнар буенча процентлар түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен 2015 елда субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2009-2015 елларда 1 елга кадәрге срокка Россия кредит оешмаларында һәм “Үсеш һәм тышкы икътисадый эшчәнлек банкы (Внешэкономбанк)” дәүләт корпорациясендә алынган кредитлар һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларында алынган заемнар буенча проңентлар түләү чыгымнарының бер олешен каплау максатларында 2015 елда федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан тыш), оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперацияләренә (алга таба – заем алучылар) бирелә.

3. Субсидияләр түбәндәге чыгымнарның бер олешен каплауга бирелә:

а) 2012 елның 31 декабренә кадәр (шул конне дә кертеп) 1 елга кадәр срокка төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

2009 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан тыш) һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары тарафыннан – ягулык-май материалларын, авыл хуҗалыгы техникасын, яңгыр яудыру һәм су сибү, насос станцияләре машиналарын, җайланмаларын һәм аппаратларын, насос станцияләрен ремонтлау өчен запас частьләр һәм материаллар, минераль ашламалар, үсемлекләрне яклау чараларын, азыкларны, ветеринария препаратларын

һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслаган исемлек нигезендә сезонлы эшләр башкару өчен башка матди ресурсларны, шулай ук яшь авыл хуҗалыгы терлеген сатып алуга, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен иминләштергәндә иминият кертемнәрен түләүгә;

2009 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмалары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперацияләренә тарафыннан – беренчел һәм сәнәгать эшкәртүе очен үзебездә җитештерелгән авыл хуҗалыгы чималын сатып алуга;

б) 2013 елның 1 гыйнварыннан алып 2015 елның 31 июленә кадәр (шул конне дә кертеп) 1 елга кадәр срокка тозелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан тыш) һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары тарафыннан – ягулык-май материалларын, үсемлекләрне саклау чараларын, минераль ашламаларны, орлыкларны (элиталы орлыклардан тыш), сугару өчен кулланыла торган электр энергиясен, авыл хуҗалыгы техникасын, җиһазларны, йөк автомобильләрен һәм тракторларны, сугаруның тамчы системалары өчен кулланыла торган материалларны, яшь авыл хуҗалыгы терлеген, азыкларны, ветеринария препаратларын сатып алуга, авыл хуҗалыгы продукциясен иминләштергәндә иминият кертемнәрен түләүгә;

оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмалары һәм кулланучылар кооперацияләре оешмалары тарафыннан – соңыннан яңадан эшкәртү өчен шикәр чөгендерен, җиләк-җимеш һәм яшелчә консерва сәнәгате өчен чимал дөгене, яшелчә, гөмбә һәм җиләк-җимешләрне, ашлык сугу, ипи пешерү һәм катнаш азык сәнәгате өчен икмәкне, май сәнәгате өчен майлы культуралар орлыкларын, каты һәм ярымкаты сырлар җитештерү өчен чимал сөт, сыер маен һәм коры сөт продуктларын, сугым чалу урыннарында чалу өчен авыл хуҗалыгы терлеген сатып алуга;

в) 2015 елның 1 августыннан башлап 1 елга кадәр срокка төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан тыш) һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары тарафыннан – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә үсемлекчелекнең кече тармакларын үстерү максатларына;

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларыннан тыш) һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары тарафыннан – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә терлекчелекнең кече тармакларын үстерү максатларына;

авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүче оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар, кулланучылар кооперациясе

оешмалары тарафыннан – үсемлекчелек продукциясенең авыл хуҗалыгы чималын беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртү өчен сатып алуга һәм авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрдән терлекчелек продукциясенең, үсемлекчелек (яшелчәчелек, бакчачылык, виноградчылык, бәрәңге үстерү тармагы, бахча культураларын үстерү тармагы һәм ябык грунт) продукциясенең авыл хуҗалыгы чималын беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртү өчен Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә сатып алуга;

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы куллнучылар кооперативларыннан тыш) һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары тарафыннан – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә үсемлекчелектә селекция-орлыкчылык үзәкләрен һәм терлекчелектә селекция-генетика үзәкләрен үстерү максатларына.

4. 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча кредитлардан (заемнардан) файдалану срокларын озайту турында килешү имзаланган очракта:

әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы “а” пунктчасында каралган 2009 елның 1 гыйнварыннан башлап төзелгән кредитлар (заемнар) буенча чыгымнарның бер өлешен каплау мондый шартнамәләрнең срогын 6 айдан артмаган вакытка озайтып башкарыла;

авыл хуҗалыгы продукцияләренә 2010 елгы корылык зыян китергән авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары тарафыннан әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы “а” пунктчасында каралган һәм 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча чыгымнарның бер өлешен каплау мондый шартнамәләрнең срогын 3 елдан артмаган вакытка озайтып башкарыла.

2014 елның 1 июленнән башлап 2015 елның 1 июленә кадәр вакыт аралыгында әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы “б” пунктчасында каралган һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы раслый торган исемлек нигезендә үсемлекчелекнең кече тармакларын үстерү максатларына алынган 2014 елда төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча чыгымнарның бер өлешен каплау мондый шартнамәләрнең срогын 1 елдан артмаган вакытка озайтып башкарыла;

5. Әлеге Тәртипнең 4 пункты нигезендә шартнамәне озайтуның чик срогын билгеләгәндә әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән чик срокларда башкарылган озайту исәпкә алынмый.

6. Заем алучыларга чыгымнарының бер өлешен каплау өчен бирелә торган субсидиянең күләме заем алучыларның кредитлар (заемнар) буенча факттагы процентлар түләү чыгымнарыннан, шулай ук заемга алучы белән Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) арасында төзелә торган килешүдә күрсәтелгән агымдагы елга исәпләнгән субсидиянең чик күләменнән күбрәк булырга тиеш түгел.

7. Заем алучыларга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр аларның төп бурычны түләп бетерү һәм исәпләнгән процентларны түләү, шулай ук кредитны (заемны) максатчан билгеләнешендә файдалану йөкләмәләре үтәлгән очракта бирелә.

Төп бурычны түләп бетерү һәм исәпләнгән процентларны түләү йөкләмәләре бозылу аркасында исәпләнгән һәм түләнгән процентларны түләү чыгымнары өлешен каплау өчен субсидияләр бирелми.

Әгәр заем алучы кредитны (заемны) чит ил валютасында алган булса, чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр кредит буенча процентлар түләү көненә чит ил валютасына карата сумның Россия Федерациясе Үзәк банкы билгеләгән курсыннан чыгып бирелә. Чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр күләмен исәпләгәндә, чит ил валютасында алынган кредитның (заемның) чик процент ставкасы еллык 10,5 процент күләмендә, ә 2015 елның 1 гыйнварыннан башлап алынган кредитлар (заемнар) буенча - еллык 10 процενттан артык булмаган күләмдә билгеләнә.

8. Заем алучыларга процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау түбәндәгечә башкарыла:

а) әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы “а” пунктчасында каралган кредитлар (заемнар) буенча - Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәп ставкасы) 80 проценты күләмендә, ә мөгезле эре терлек итен һәм сөт җитештерү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы куллануччылар кооперативларыннан тыш) алган кредитлар (заемнар) буенча - Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәп ставкасы) 100 проценты күләмендә;

б) әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы “б” пунктчасында каралган кредитлар (заемнар) буенча - Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәп ставкасы) өчтән ике өлеше күләмендә, сөт җитештерү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан һәм авыл хуҗалыгы куллануччылар кооперативларыннан тыш) сөт терлекчелеген үстерүгә алган кредитлар (заемнар) буенча - Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәп ставкасы) 80 проценты күләмендә; мөгезле эре терлек итен җитештерү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар һәм авыл хуҗалыгы куллануччылар кооперативларыннан тыш) сөт терлекчелеген, мөгезле эре терлек итен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать) эшкәртүне дә кертеп, үстерүгә, шулай ук үсемлекчелектә селекция-орлыкчылык үзәкләрен һәм терлекчелектә селекция-генетика үзәкләрен үстерүгә алган кредитлар (заемнар) буенча - Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәп ставкасы) 100 проценты күләмендә;

в) әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы “а” - “в” пунктчаларында каралган 2015 елда процентлар түләү (вакытыннан алда түләп бетерелгән процентларны да кертеп) чыгымнарының бер өлешен каплау өчен алынган кредитлар (заемнар) буенча 2015 елда субсидияләр – субсидияләү ставкасы күләмендә ($СС_{1j}$), ул түбәндәге формула

буенча билгеләнә:

$$CC_{1j} = CT_{реф} \times 1{,}1 + KC - INF,$$

монда:

$CT_{реф}$ – 2015 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасы (исәп ставкасы) (8,25%), ә 2015 елның 1 августыннан башлап – кредит шартнамәсен (заем шартнамәсен) төзү яисә кредит шартнамәсенә (заем шартнамәсенә) кредиттан (заемнан) файдаланган очен түләү күләме үзгәрүгә бәйле өстәмә килешү төзү датасына булган ставкасы;

КС – 2015 елның 1 гыйнварына Россия Федерациясе Үзәк банкының төп ставкасы (17%), ә 2015 елның 1 августыннан башлап – кредит шартнамәсен (заем шартнамәсен) төзү яисә кредит шартнамәсенә (заем шартнамәсенә) кредиттан (заемнан) файдаланган өчен түләү күләме үзгәрүгә бәйле өстәмә килешү төзү датасына булган ставкасы;

INF – Федераль дәүләт статистика хезмәте мәгълүматлары буенча 2014 елгы инфляция дәрәҗәсе (11,4%);

г) әгәр әлеге пунктның “а” - “в” пунктчалары буенча исәпләнгән субсидияләү ставкасы күләме ($CC_{1j}$) әлеге Тәртипнең 8 пунктындагы “а” - “в” пунктчаларында күрсәтелгән субсидияләр күләменнән азрак булса, субсидияләрнең күләмен исәпләү әлеге Тәртипнең 8 пунктына нигезләнеп башкарыла.

9. Субсидияләрнең күләмен исәпләү, максатчан билгеләнешендә кулланылган кредит (заем) суммасыннан чыгып, кредит шартнамәсен (заем шартнамәсен) төзегән көнгә, ә кредит шартнамәсенә (заем шартнамәсенә) кредиттан (заемнан) файдаланган өчен түләү арту белән бәйле өстәмә килешү тозелгән очракта – кредит шартнамәсенә (заем шартнамәсенә) өстәмә килешү төзегән көнгә гамәлдә булган Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасы буенча башкарыла.

10. Субсидияләр алу өчен, заем алучы Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба – Идарә) килештерү өчен түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык раслаган форма буенча, түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

кредит шартнамәсенең (заем шартнамәсенең) кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләрен, кредит (заем) алу турында ссуда счетыннан өземтәне, түләп бетерү һәм аның буенча процентлар түләү гарфигын;

товарлар сатып алу һәм хезмәт күрсәтү шартнамәләренең, накладнойларның заем алучы тарафыннан таныкланган күчермәләрен яки накладнойлар реестрын (накладнойларның исәбе 20 данәдән артып китсә), авыл хуҗалыгы продукциясен иминләштерү шартнамәләренең һәм авыл хуҗалыгы продукциясен иминләштергәндә иминият кертемнәрен түләү счетларының күчермәләрен – кредиттан файдалану дәрәҗәсенә карап;

банктан өземтәләрнең һәм товарлар, хезмәт күрсәтүләр өчен түләүне, аванс түләүләрен дә кертеп, раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләрен;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр күләменең исәп-хисабын (субсидияләр элек финансланган чорлар өчен бирелгән һәм яңадан исәпләнми торган исәп-хисаплар буенча түләнә);

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр күләменең планлаштырылган исәп-хисабын;

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча кредитны (заемны) түләп бетерү һәм аның буенча проңентлар түләү графигын.

Әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы “а” - “в” пунктчаларында каралган кредитлар (заемнар) буенча әлеге Тәртипнең 10 пунктында күрсәтелгән документлар заем алучы тарафыннан 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап кредит шартнамәсенең гамәлдә булу срогы чыкканнан соң 6 айдан да соңга калмыйча вәкаләтле органга тапшырыла.

Вәкаләтле орган заем алучы тапшырган документларны тикшерә, заем алучы гаризасын гаризалар керү тәртибендә теркәү журналында терки, аңа номер сугыла, тегеп куела һәм әлеге органның мөһере сугыла, һәм заем алучыга кабул ителгән документларны теркәгән көннән соң 10 көн эчендә гаризаны карауга кабул итү турында яки, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, аны кабул итүдән баш тарту турында язма хәбәр юллый.

Вәкаләтле орган заем алучы тарафыннан субсидияләр алу өчен тапшырылган документларны 10 эш көне эчендә карый.

Кредитлар (заемнар) буенча проңентлар түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга заем алучыга субсидияләр бирүдән баш тарткан очракта, вәкаләтле орган теркәү журналыа тиешле язма кертә, мондый очракта заем алучыга 10 көн эчендә тиешле язма хәбәр юллана.

11. Заемга алучы үз теләге белән салым һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча срогы чыккан бурычлары булмау турында салым органы белешмәсен тапшырырга хокуклы.

Әгәр заем алучы күрсәтелгән документны үз теләге белән тапшырмаса, Министрлык аны ведомствоара сорату юлы белән Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча бүлегеннән соратып ала.

12. Идарә заем алучылар тапшырган документларны тикшерә, субсидияләрнең күләмен исәпләүләрне 2 көн эчендә килештерә һәм аларны заем алучыга кире кайтара.

13. Заем алучы Идарә тарафыннан килештерелгән, әлеге Тәртипнең 10 пунктында күрсәтелгән документларны Министрлыкка агымдагы айның 1 нче числосыннан алып 20 нче числосына кадәр тапшыра.

Министрлык:

заем алучы гаризасын, гаризалар керү тәртибен саклап, журналга терки, ул номерлана, шнурлана һәм аңа Министрлык мөһере сугыла;

кабул ителгән документларны теркәгән көннән соң өч көн эчендә аларны карауга кабул итү турында яки аны кабул итүдән баш тарту турында, моның сәбәбен күрсәтеп, язма хәбәр юллый;

заем алучы тарафыннан тапшырылган документларны 3 эш көне эчендә тикшерә.

Заем алучыга әлеге Тәртипнең “а” һәм “б” пунктчаларында каралган кредитлар (заемнар) буенча процентлар түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирүдә баш тартылса, Министрлык теркәү журналына тиешле язма кертә, заем алучыга исә ун көн эчендә тиешле язма хәбәр юллана.

14. Документларны карауга алуда түбәндәге очракларда баш тартыла:

әлеге Тәртипнең 10 пунктында күрсәтелгән документлар Министрлыкка заем алучылар тарафыннан тапшырылмаганда яки вакытында тапшырылмаганда.

Субсидияләр бирүдә түбәндәге очракларда баш тартыла:

Министрлыкка бу максатларга тиешле финанс елына каралган бюджет йөкләмәләре лимитлары булмаганда;

тапшырылган документлар субсидияләр бирү шартларына туры килмәгәндә;

тапшырылган документларда дөрес булмаган белешмәләр булганда.

Субсидияләр бирүдән баш тартуга шикаять Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә агымдагы ел дәвамында бирелә.

15. Субсидияләрне күчерү Министрлыкның Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган хосусый счетыннан заем алучыларның исәп-хисап счетларына Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр күләме исәп-хисабына нигезләнеп 5 эш көне эчендә башкарыла.

16. Алынган субсидияләр субсидияләрнең максатчан билгеләнеше буенча файдаланмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң, Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән башлап алтмыш көн эчендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

17. Субсидия бирү турында килешүләрдә каралган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр федераль бюджет керемнәренә субсидияләр алучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

18. Күрсәтелгән акчаларны федераль бюджетка үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә кире кайтарылырга тиеш.

19. Министрлык һәм (яки) дәүләт финанс контроле органы авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

20. Кредитларның һәм заемнарның максатчан кулланылышын раслый торган, заем алучылар тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә, туры килү буенча, аларның вазыйфаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

21. Бюджет акчаларының максатка ярашлы кулланылышын Министрлык тикшереп тора.

2015 елның 17.08 194/2 -пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгына
2 нче кушымта

2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгына
8 нче кушымта

Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмаларына, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына 2 елдан алып 15 елга кадәрге срокка алынган инвестиция кредитлары буенча процентлар түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен
2015 елда субсидияләр бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2004-2015 елларда 2 елдан алып 15 елга кадәрге срокка Россия кредит оешмаларында һәм "Үсеш һәм тышкы икътисадый эшчәнлек банкы (Внешэкономбанк)" дәүләт корпорациясендә алынган кредитлар һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларында алынган заемнар (алга таба – кредитлар, заемнар) буенча процентлар түләү чыгымнарының бер өлешен каплау максатларында 2015 елда федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына, авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать шартларында) эшкәртүне гамәлгә ашыручы оешмаларга һәм индивидуаль эшкуарларга (алга таба – заем алучылар) бирелә.

3. Субсидияләр түбәндәге чыгымнарның бер өлешен каплауга бирелә:

а) түбәндәгеләр тарафыннан алынган инвестиция кредитлары (заемнары), буенча:

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать шартларында) эшкәртүне гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар, крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары тарафыннан түбәндәге чорларда төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

2004 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 2 елдан алып 8 елга кадәр срокка (оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә ит өчен терлек үрчетү һәм (яки) сөт җитештерү белән шөгыльләнүче агросәнәгать комплексы оешмаларыннан тыш) – җиһазлар, махсуслаштырылган транспорт, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы

тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә махсус техника, йөк автомобильләрен, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын газ-мотор ягулыгына күчерү өчен җиһазлар һәм нәселлек продукцияләрен (материалын) сатып алуга, шулай ук күпьеллык үсемлекләр һәм виноградлыклар утыртуга, күпьеллык үсемлекләр өчен ялгау комплексларын төзүгә, реконструкцияләүгә, терлекчелек комплексларын (фермаларын), терлекчелек, азык җитештерү объектларын, бәрәңге базларын, яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр саклау урыннарын, ябык грунтта җиләк-җимеш, яшелчә продукциясен җитештерү буенча теплица комплексларын, җитенне һәм җитен сүсен эшкәртү объектларын, ит саклау урыннарын, авыл хуҗалыгы терлеген һәм сөтне кабул итү һәм (яки) беренчел эшкәртү пунктларын, моңа ит һәм сөт продукциясен суыту да керә, төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә, шулай ук протеиннарга бай авыл хуҗалыгы культураларын (кытай борчагы, бодай, арыш, кукуруз, рапс, нут һәм сарго) тирән эшкәртү объектларын төзүгә;

2004 елның 1 гыйнварыннан алып 2008 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 2 елдан алып 8 елга кадәр срокка – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә авыл хуҗалыгы техникасын сатып алуга;

2009 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 8 елга кадәр срокка – авыл җирендә яшәүче һәм эшләүче гражданнар өчен торак төзүгә;

2010 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 8 елга кадәр срокка – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә яңгыр яудыру һәм су сибү, насос станцияләре машиналарын, җайланмаларын һәм аппаратларын сатып алуга;

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) 2008 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 10 елга кадәр срокка төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча һәм 2008 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 15 елга кадәр срокка ит һәм (яки) сөт өчен терлек үрчетүне үстерүгә алынган кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә авыл хуҗалыгы техникасын сатып алуга;

авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать шартларында) эшкәртүне, ашлык һәм май культураларын хәзерләп кую, саклау һәм күчерүне гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 2010 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 10 елга кадәр срокка төзелгән түбәндәге кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

ашлык һәм май культураларын хәзерләп кую, саклау һәм күчерү өчен куәтләр төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә;

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә ашлык һәм май культураларын хәзерләп кую, саклау һәм күчерү өчен җиһазлар сатып алуга (монтаж һәм көйләп җибәрү эшләрен дә кертеп);

авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать шартларында) эшкәртүне гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

2009 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 8 елга кадәр срокка – шикәр заводларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә;

2010 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 8 елга кадәр срокка – шикәр чөгендереннең борчакландырылган орлыкларын җитештерү заводларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә;

2011 елның 1 гыйнварыннан алып 2011 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 8 елга кадәр срокка – авыл хуҗалыгы үсемлекләре орлыкларын әзерләү һәм эшкәртү буенча мелиоратив системалар, заводлар, комплекслар төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү һәм торгызуга;

оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә товар (сәнәгать шартларында) балык үрчетү белән шөгыльләнүче оешмалар тарафыннан 2007 елның 1 гыйнварыннан алып 2011 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, түбәндәге срокка срокка төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

5 елга кадәр срокка – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә товар (сәнәгать шартларында) балык үрчетү өчен нәселле балык материалын, техниканы һәм җиһазларны сатып алуга;

8 елга кадәр срокка – товар (сәнәгать шартларында) балык үрчетүне башкару буенча комплекслар (фермалар) төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә;

оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә йортлаштырылган балык төрләрен һәм токымнарын үрчетү белән шөгыльләнүче оешмалар тарафыннан 2012 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, түбәндәге срокка срокка төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

5 елга кадәр срокка – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә йортлаштырылган балык төрләрен һәм токымнарын үрчетү өчен нәселле балык материалын, техниканы һәм җиһазларны сатып алуга;

8 елга кадәр срокка – йортлаштырылган балык төрләрен һәм токымнарын үрчетүне башкару буенча комплекслар (фермалар) төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә;

ит өчен терлек үрчетү һәм (яки) сөт җитештерү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товарларын җнтештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), оештырылу-хокук рәвешләренең нинди булуына бәйсез рәвештә агросәнәгать комплексы оешмалары, крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары тарафыннан 2004 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 15 елга кадәр срокка – җиһазлар, махсуслаштырылган транспорт, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә махсус

техника, йөк автомобильләрен, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын газ-мотор ягулыгына күчерү өчен җиһазлар һәм нәселлек продукцияләрен (материалын) сатып алуга, шулай ук терлекчелек комплексларын (фермаларын), терлекчелек һәм азык җитештерү объектларын, ит чалу-суыту биналарын, авыл хуҗалыгы терлеген һәм сөт кабул итү һәм (яки) беренчел эшкәртү пунктларын (моца ит һәм сөт продукциясен суыту һәм саклау да керә);

б) 2013 елның 1 гыйнварыннан алып 2015 елның 31 июленә кадәр, шул көнне дә кертеп, төзелгән инвестицияле кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать шартларында) эшкәртүне гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 2 елдан алып 8 елга кадәр срокка төзелгән:

- бәрәңге базларын, яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр саклау урыннарын, ябык грунтта җиләк-җимеш, яшелчә продукциясен җитештерү буенча теплица комплексларын, ашлык сугу, ипи пешерү һәм май сәнәгате предприятиеләрен, шикәр заводларын, яшелчә, җиләк-җимеш, виноград һәм бәрәңге продукциясен эшкәртү куәтләрен, җитенне һәм җитен сүсен эшкәртү объектларын, авыл хуҗалыгы үсемлекләренең орлыкларын хәзерләү комплексларын, шикәр чөгендеренең борчакландырылган орлыкларын җитештерү заводларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә, протеиннарга бай авыл хуҗалыгы культураларын тирән эшкәртү объектларын, ашлык һәм май культураларын хәзерләп кую, саклау һәм күчерү, күпьеллык үсемлекләрне утырту һәм карау куәтләрен төзүгә, күпьеллык үсемлекләр өчен ялгау комплексларын төзү һәм реконструкцияләүгә, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә үсемлекчелек тармакларын үстерү максатларына, шулай ук мелиорация системаларын төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү һәм торгызуга (мелиорация системаларын төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү һәм торгызуга алынган инвестиция кредитларын субсидияләү 2015 елның 31 июленә кадәр, шул көнне дә кертеп, гамәлгә ашырыла);

мелиорация системаларын төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү һәм торгызуга (мелиорация системаларын төзү, реконструкцияләү, модернизацияләү һәм торгызуга алынган инвестиция кредитларын субсидияләү 2013 елның 31 декабренә кадәр гамәлгә ашырыла);

үсемлекчелектә файдаланыла торган авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазларын сатып алуга (код ОКП 472000, 473000);

терлекчелектә файдаланыла торган авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазларын сатып алуга (код ОКП 472000, 473000);

терлекчелектә (шул исәптән авыл хуҗалыгы терлеген сату буенча һәм үсемлекчелектә) логистик үзәкләр төзүгә;

ит өчен терлек үрчетүне үстерү буенча хуҗалык эшчәнлеген тәэмин итү максатларында файдаланыла торган авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазларын;

үз ана башлар көтүен булдыру өчен ит токымнары мөгезле эре терлегенең товар ремонт яшь терлеген сатып алуга;

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать шартларында) эшкәртүне гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар (ит һәм (яки) сөт өчен терлек үрчетү белән шөгыльләнүче оешмалардан тыш) тарафыннан 2 елдан алып 8 елга кадәр срокка – терлекчелек комплексларын (фермаларын), объектларын, ит саклау урыннарын, авыл хуҗалыгы терлеген һәм сөтне кабул итү, беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать шартларында) эшкәртү пунктларын, сөт продукциясен, сырларны һәм сыер маен җитештерү предприятиеләрен, эремчек суын эшкәртү һәм киптерү цехларын һәм участокларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә, катнаш азык предприятиеләрен һәм цехларын төзү һәм реконструкцияләүгә, нәсел продукциясен сатып алуга, шулай ук Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә терлекчелекнең кече тармакларын үстерү максатларына;

ит өчен терлек үрчетү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать шартларында) эшкәртүне гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 15 елга кадәр срокка - ит токымнары мөгезле эре терлегенең нәсел продукциясен (материалын) сатып алуга, терлекчелек комплексларын (фермаларын), объектларын, ит саклау урыннарын, кабул итү, беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать шартларында) эшкәртү пунктларын, шулай ук Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә ит өчен терлек үрчетүне үстерү максатларына;

сөт очен терлек үрчетү белән шөгыльләнүче авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать шартларында) эшкәртүне гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 15 елга кадәр срокка – терлекчелек комплексларын (фермаларын), объектларын, сөт кабул итү, беренчел эшкәртү (моңа сөт продукциясен суыту һәм саклау да керә) пунктларын, эшкәртелмәгән сөт продукциясен, сырларны һәм сыер маен җитештерү предприятиеләрен, эремчек суын эшкәртү һәм киптерү цехларын һәм участокларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә, катнаш азык предприятиеләрен һәм цехларын төзү һәм реконструкцияләүгә, нәсел продукциясен сатып алуга, шулай ук Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә терлекчелекнең кече тармагын үстерү максатларына;

в) авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм

крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать шартларында) эшкәртүне гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 2015 елныц 1 гыйнварыннан башлап төзелгән инвестицияле кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча 8 елга кадәрге срокка - үсемлекчелектә (үсемлек авыруларын китереп чыгара торган сәбәпләрне ачыклау очен диагностика җайланмалары), терлекчелектә һәм азык җитештерүдә (азыкның сыйфатын яхшырту өчен биологик өстәмә катнашмалар (аминокислоталар, азык аксымы, ферментлар, витаминнар, пробиотиклар), туклану һәм эшкәртү сәнәгатендә (крахмаллар һәм глюкоза – җиләк-җимеш сироплары, сөт, сөт-май, ит эшкәртү производстволары өчен ферментлар һәм микроорганизмнар, органик кислоталар (лимон, сөт һәм селте), азык чималын тирән эшкәртү продуктлары, биоягулык) биотехнологик продукция җитештерү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә;

в[1]) 2015 елныц 1 августыннан башлап төзелгән инвестицияле кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать шартларында) эшкәртүне гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 2 елдан алып 8 елга кадәрге срокка – бәрәңге базларын, яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр саклау урыннарын, ябык грунтта җиләк-җимеш, яшелчә продукциясен җитештерү буенча теплица комплексларын, ашлык сугу, ипи пешерү һәм май сәнәгате предприятиеләрен, шикәр заводларын, яшелчә, җиләк-җимеш, бәрәңге продукциясен эшкәртү куәтләрен, җитенне һәм җитен сүсен эшкәртү объектларын, авыл хуҗалыгы үсемлекләренец орлыкларын хәзерләү комплексларын, шикәр чөгендеренец борчакландырылган орлыкларын җитештерү заводларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә, протеиннарга бай авыл хуҗалыгы культураларын тирән эшкәртү объектларын, ашлык һәм май культураларын хәзерләп кую, саклау һәм күчерү, күпьеллык үсемлекләрне, виноградлыкларны да кертеп, утырту һәм карау куәтләрен төзүгә, күпьеллык үсемлекләр өчен ялгау комплексларын төзү һәм реконструкцияләүгә, шулай ук Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә башка төр инвестиция чыгымнарына, шул исәптән техника, җиһазлар, автомобиль сәнәгате эшләнмәләрен сатып алуга;

авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать шартларында) эшкәртүне гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 2 елдан алып 8 елга кадәрге срокка (ит һәм сөт өчен терлек үрчетүне үстерүгә алынган кредитлардан тыш) – терлекчелек комплексларын (фермаларын), объектларын, ит саклау урыннарын, авыл хуҗалыгы терлеген һәм сөтне кабул итү, беренчел һәм (яки) аннан соцгы (сәнәгать шартларында) эшкәртү (ит һәм сөт продукциясен суыту һәм саклауны да кертеп) пунктларын, эшкәртелмәгән сөт продукциясен, сырларны һәм сыер маен җитештерү

предприятиеләрен, эремчек суын эшкәртү һәм киптерү цехларын һәм участокларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә, катнаш азык предприятиеләрен һәм цехларын төзү һәм реконструкцияләүгә, нәсел продукциясен сатып алуга, шулай ук Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә башка төр инвестиция чыгымнарына, шул исәптән техника, җиһазлар, автомобиль сәнәгате эшләнмәләрен сатып алуга;

авыл хуҗалыгы товарларын җнтештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соцгы (сәнәгать шартларында) эшкәртүне гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 15 елга кадәрге срокка – ит токымнары мөгезле эре терлегенец нәсел продукциясен (материалын) сатып алуга, терлекчелек комплексларын (фермаларын), объектларын, ит саклау урыннарын, кабул итү, беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать шартларында) эшкәртү, ит продукциясен суыту һәм саклауны да кертеп, пунктларын, шулай ук Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә башка төр инвестиция чыгымнарына, шул исәптән техника, җиһазлар, автомобиль сәнәгате эшләнмәләрен сатып алуга;

авыл хуҗалыгы товарларын җнтештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соцгы (сәнәгать шартларында) эшкәртүне гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 15 елга кадәрге срокка (сөт өчен терлек үрчетүне үстерүгә алынган кредитлар буенча) – терлекчелек комплексларын (фермаларын), объектларын, ит саклау урыннарын, сөтне кабул итү, беренчел һәм (яки) аннан соцгы (сәнәгать шартларында) эшкәртү (сөт продукциясен суыту һәм саклауны да кертеп) пунктларын, эшкәртелмәгән сөт продукциясен, сырларны һәм сыер маен җитештерү предприятиеләрен, эремчек суын эшкәртү һәм киптерү цехларын һәм участокларын төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә, катнаш азык предприятиеләрен һәм цехларын төзү һәм реконструкцияләүгә, нәсел продукциясен сатып алуга, шулай ук Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә башка төр инвестиция чыгымнарына, шул исәптән техника, җиһазлар, автомобиль сәнәгате эшләнмәләрен сатып алуга;

авыл хуҗалыгы товарларын җнтештерүчеләр (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш), авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соцгы (сәнәгать шартларында) эшкәртүне гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 2 елдан алып 8 елга кадәрге срокка – үсемлекчелектә селекция-орлыкчылык үзәкләрен төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә, ә 15 елга кадәрге срокка – терлекчелектә селекция-генетика үзәкләрен төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә, шулай ук Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә башка төр инвестиция чыгымнарына, шул исәптән техника, җиһазлар,

автомобиль сәнәгате эшләнмәләрен сатып алуга;

Россия оешмалары тарафыннан 2 елдан алып 8 елга кадәрге срокка – күпләп сату-бүлү үзәкләрен, болар: авыл хуҗалыгы продукциясен, чималын һәм азык-төлекне саклау, хәзерләү, беренчел эшкәртү, кабул итү, торү һәм сату өчен, шул исәптән Россия Федерациясендә халыкның мохтаҗ катламнарына эчке азык-төлек ярдәме системасында, автоматлаштырылган электрон мәгълүмат һәм исәп-хисап системаларын кулланып, аларга шул исәптән инженерлык-техник тәэминатның эчке һәм тышкы челтәрләре керә, ветеринар һәм фитосанитар контроль башкару өчен билгеләнгән биналар, төзелмәләр һәм корылмалар төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләүгә, шулай ук Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә техника, җиһазлар сатып алуга;

г) әлеге пунктның “а” - “в[1]” пунктчаларында каралган кредитларны (заемнарны) рефинанслауга алынган кредитлар (заемнар) буенча, кредитлардан (заемнардан) файдалануның бергә кушылган сроклары әлеге пунктчаларда күрсәтелгән сроклардан артып китмәсә.

Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр һәм авыл хуҗалыгы продукциясен беренчел һәм (яки) аннан соңгы (сәнәгать шартларында) эшкәртүне гамәлгә ашыручы оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан әлеге пунктның “а” - “в[1]” пунктчалары нигезендә тотылган чыгымнарны, аларны түләү чыганакларын акционер, облигация заемнары тәшкил итә, рефинанслауга (каплауга) алынган һәм 2015 елның 1 гыйнварыннан соң бирелгән кредитлар (заемнар) буенча, кредитлардан (заемнардан) файдалануның бергә кушылган сроклары әлеге пунктчаларда күрсәтелгән сроклардан артып китмәсә.

4. 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча кредитлардан (заемнардан) файдалану срокларын озайту турында килешү имзаланган очракта:

әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы “а” пунктчасының дүртенче абзацында каралган 2004 елның 1 гыйнварыннан башлап төзелгән кредитлар (заемнар) буенча чыгымнарның бер олешен каплау мондый шартнамәләрнең срогын 3 елдан артмаган вакытка озайтып башкарыла;

авыл хуҗалыгы продукцияләренә 2010 елгы корылык зыян китергән авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары тарафыннан әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы “а” пунктчасының дүртенче абзацында каралган һәм 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча чыгымнарның бер олешен каплау мондый шартнамәләрнең срогын иң күбе 3 елга озайтып башкарыла;

әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы “а” - “в[1]” пунктчаларында каралган кредит (заем) шартнамәләре буенча кредитлардан (заемнардан) файдалану срокларын озайту турында килешү 2015 елның 1 гыйнварыннан алып 2015 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, имзаланган очракта, мондый шартнамәләр буенча чыгымнарның бер өлешен кайтару аларны иң күбе 1 елга озайтып башкарыла.

5. Әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә шартнамәне озайтуның чик срогын билгеләгәндә әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән сроклар чигендә башкарылган озайту исәпкә алынмый.

6. Заем алучыларга чыгымнарының бер олешен каплауга субсидияләр түбәндәге шартлар үтәлгәндә бирелә:

а) заем алучы министрлык белән инвестицияле кредитлар (заемнар) буенча процентлар түләү чыгымнарының бер олешен каплауга субсидияләр бирү турында килешү төзегәннән соң, анда әлеге чараларның инвестицияле кредит шартнамәсе (заем шартнамәсе) гамәлдә булган чорга еллык чик исәп-хисап күләмен билгеләү карала, шулай ук объектны кулланышка кертү срокларына (кулланышка кертү таләп ителгән объектлар буенча);

б) алар төп бурычны каплау һәм исәпләнгән процентларны түләү һәм кредитны (заемны) максатчан билгеләнешендә куллану буенча үз йөкләмәләрен үтәсә.

аларның төп бурычны түләп бетерү һәм исәпләнгән процентларны түләү һәм кредитны (заемны) максатчан билгеләнешендә файдалану йөкләмәләре үтәлгән очракта бирелә.

Төп бурычны түләп бетерү һәм исәпләнгән процентларны түләү йокләмәләре бозылу аркасында исәпләнгән һәм түләнгән процентларны түләү чыгымнарыныц бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирелми.

7. Заем алучыларга процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау түбәндәгеләр буенча башкарыла:

а) әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы “а” пунктчасында каралган инвестицияле кредитлар (заемнар) буенча – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасыныц (исәп ставкасы) 80 проценты чигендә, ә ит һәм сөт өчен терлек үрчетүгә, шул исәптән авыл хуҗалыгы техникасын сатып алуга алынган кредитлар (заемнар) буенча (2008 елныц 1 гыйнварыннан алып 2012 елныц 31 декабренә кадәр чорда, шул көнне дә кертеп, 10 елга төзелгән кредит шартнамәләре буенча һәм 15 елга кадәрге чорга ит һәм сөт очен терлек үрчетүгә ярдәм итү өчен алынган кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча) – Россия Федерациясе Үзәк банкыныц рефинанслау ставкасыныц (исәп ставкасы) 100 проценты күләмендә;

б) әлеге Тәртипнец 3 пунктындагы “б” һәм “в” пунктчаларында каралган кредитлар (заемнар) буенча – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасыныц (исәп ставкасы) өчтән ике өлеше күләмендә, ә ит һәм сөт өчен терлек үрчетүне үстерүгә алынган кредитлар (заемнар) буенча – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасыныц (исәп ставкасы) 100 проценты күләмендә;

б$^{1}$) әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы “в$^{1}$” пунктчасында каралган кредитлар (заемнар) буенча – Россия Федерациясе Үзәк банкыныц рефинанслау ставкасыныц (исәп ставкасы) 100 проценты күләмендә, ә күпләп сату-бүлү үзәкләрен үстерүгә алынган кредитлар (заемнар) буенча – Россия Федерациясе Үзәк банкыныц рефинанслау ставкасыныц (исәп ставкасы) өчтән ике өлеше күләмендә;

в) әлеге Тәртипнец 3 пунктындагы “а” – “в$^{1}$” пунктчаларында каралган инвестицияле кредитлар (заемнар) буенча 2015 елныц процентларын (вакытыннан алда түләнгән процентларны да кертеп) түләү чыгымнарыныц бер өлешен

кайтаруга – Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәп ставкасы) 100 проценты күләмендә.

8. Әгәр заем алучы кредитны (заемны) чит ил валютасында алган булса, чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр кредит буенча процентлар түләү көненә чит ил валютасына карата сумның Россия Федерациясе Үзәк банкы билгеләгән курсыннан чыгып бирелә.

Чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр исәпләгәндә, чит ил валютасында алынган кредитның (заемның) чик процент ставкасы еллык 10,5 процент күләмендә, ә 2015 елның 1 гыйнварыннан башлап алынган кредитлар (заемнар) буенча – иң күбе еллык 10 процент күләмдә билгеләнә.

9. Заем алучыларга чыгымнарының бер өлешен каплау өчен бирелә торган субсидиянең күләме заем алучыларның кредитлар (заемнар) буенча факттагы процентлар түләү чыгымнарыннан, шулай ук заемга алучы белән Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы (алга таба – Министрлык) арасында төзелә торган килешүдә күрсәтелгән агымдагы елга исәпләнгән субсидиянең чик күләменнән күбрәк булырга тиеш түгел.

10. Субсидияләрнең күләмен исәпләү, максатчан билгеләнешендә кулланылган кредит (заем) суммасыннан чыгып, кредит шартнамәсен (заем шартнамәсен) төзегән көнгә, ә кредит шартнамәсенә (заем шартнамәсенә) кредиттан (заемнан) файдаланган өчен түләү арту белән бәйле өстәмә килепү төзелгән очракта – кредит шартнамәсенә (заем шартнамәсенә) өстәмә килешү төзегән көнгә гамәлдә булган Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасы буенча башкарыла.

11. Әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы “а” – “в” пунктчаларында каралган кредитлар (заемнар) буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләр алу өчен, заем алучы Министрлыкның Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба – Идарә) килештерү өчен, кредит (заем) буенча процентлар фактта түләнгәннән соң 3 айдан да соңга калмыйча, түбәндәге документларны тапшыра:

а) Министрлык раслаган форма буенча, кредит оешмасы тарафыннан таныкланган түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

б) түләү йөкләмәсенең (яки башка төрле банк документының) һәм заем алучының ссуда счетыннан аның кредит алуы турында өземтәнең күчермәләрен яисә заем алуын раслый торган башка документны, болар барысы да кредит оешмасы тарафыннан таныкланган булырга тиеш;

в) агымдагы айның процентларын түләүгә түләү йөкләмәләренең (яки түләүне раслый торган башка төрле банк документларының) кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләрен;

г) кредитны (заемны) каплау һәм аның буенча процентлар түләүнең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган графигын;

д) әлеге Боерыкның 13 пунктында каралган исемлек буенча кредитның (заемның) максатчан билгеләнешендә кулланылуын раслый торган документларның күчермәләрен – кредиттан файдалану дәрәҗәсенә карап;

е) Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр исәп-хисабын (субсидияләр элек финансланган чорлар өчен бирелгән һәм яңадан исәпләнми торган исәп-хисаплар буенча түләнә);

ж) түләнми калган салымнар булмауны раслый торган документларның салым органы тарафыннан расланган күчермәләрен бирергә хокуклы.

Әгәр заем алучы күрсәтелгән документны үз ихтыяры белән тапшырмаса, вәкаләтле орган ведомствоара сорату аркылы, шул исәптән ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм тоташа торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып, заем алучының салымнар, җыемнар, пенялар түләү буенча бурычлары һәм Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнарын бозган өчен штрафлары булу (булмау) турында белешмәләрне Федераль салым хезмәтеннән соратып ала (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш).

з) Министрлык тарафыннан расланган форма буенча кредит акчаларының тотылуы турында белешмәне.

Заем алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы “а” – “в” пунктчаларында каралган кредитлар (заемнар) буенча әлеге пунктта санап кителгән документлар кредит шартнамәсе төзелгән көннән башлап 6 ай эчендә вәкаләтле органга тапшырылырга тиеш.

12. Заем алучы үз теләге белән салымнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасының бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча түләнми калган бурычлары булмау турында салым органы белешмәсен тапшырырга хокуклы (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш). Әгәр заем алучы күрсәтелгән документны үз ихтыяры белән тапшырмаса, Министрлык аны ведомствоара сорату юлы белән Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча бүлегеннән сорат ып ала.

13. Кредитның (заемның) максатчан билгеләнешендә кулланылуын раслый торган документларның заем алучы тарафыннан таныкланган күчермәләре, кредиттан (заемнан) файдалану дәрәҗәсенә карап түбәндәгеләрне тапшыра:

Россия дәүләт стандарты оешмасының 1993 елның 30 декабрендәге 301 номерлы карары белән расланган ОК005-93 Бөтенроссия продукция классификаторы нигезендә (аңа кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып) билгеләнгән авыл хуҗалыгы техникасын, җиһазларын, махсуслаштырылган транспортны һәм махсус техниканы сатып алу өчен алынган кредитлар (заемнар) буенча:

авыл хуҗалыгы техникасы, махсуслаштырылган транспорт һәм махсус техника һәм җиһазлар өчен түләүне, аванс түләүләрен дә кертеп, раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләрен;

җиһаз өчен түләүгә аккредитив ачуны раслый торган түләү йөкләмәләренең һәм/яки документларының кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләрен;

авыл хуҗалыгы техникасын, махсуслаштырылган транспортны, махсус техниканы һәм җиһазларны сатып алу (лизингка) шартнамәләренең күчермәләрен;

авыл хуҗалыгы техникасын, махсуслаштырылган транспортны һәм махсус техниканы һәм җиһазларны сатып алуга товар-транспорт накладнойларының, счет-

фактураларының күчермәләрен;

авыл хуҗалыгы техникасын, махсуслаштырылган транспортны һәм махсус техниканы һәм җиһазларны кабул итү- тапшыру актларының күчермәләрен (№ ОС-1, № ОС-1б, № ОС-15 формалары)*;

юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе органнарында һәм дәүләт техника күзәтчелеге органнарынада теркәлү турында тамга сугылган транспорт чаралары паспортының, үзйөрешле машиналар паспортының күчермәләрен.

Россия Федерациясе территориясендә җитештерелми торган җиһазларны чит ил валютасына сатып алуны раслый торган документлар**:

чит ил җиһазын сатып алу контрактының күчермәсе;

валютаны күчерүне раслау турында свифт хәбәрләрнең күчермәләре;

йок таможнясы декларациясенең күчермәсе (йок таможнясы декларациясен законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә рәмиләштергәннән соң тапшырыла);

импорт алыш-бирешенең паспорты күчермәсе;

импорт алыш-биреше паспортының торышы турында белешмә;

җиһазларны кабул итү- тапшыру актларының күчермәләре (№ ОС-1, № ОС-1б, № ОС-15 формалары)*;

Нәселле продукцияне сатып алу өчен алынган кредитлар (заемнар) буенча:

нәселле продукция (материал) өчен түләүне, аванс түләүләрен дә кертеп, раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

нәселле продукцияне сатып алу (лизингка) шартнамәләренең күчермәләре;

нәселле продукцияне кабул итү-тапшыру актларының күчермәләре;

нәселле продукцияне сатып алу счет-фактураларының күчермәләре һәм нәсел таныклыклары реестры.

Нәселле продукцияне (материалны) чит ил валютасына сатып алуны раслый торган документлар**:

нәселле продукция (материал) өчен түләүгә аккредитив ачуны раслый торган түләү йөкләмәләренең һәм/яки документларының кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

нәселле продукцияне (материалны) сатып алу контрактының күчермәсе;

валютаны күчерүне раслау турында свифт хәбәрләрнең күчермәләре;

йөк таможнясы декларациясенең күчермәсе (йөк таможнясы декларациясен законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә рәмиләштергәннән соң тапшырыла);

импорт алыш-бирешенең паспорты күчермәсе;

импорт алыш-биреше паспортының торышы турында белешмә.

Төзү, реконструкцияләү һәм модернизацияләү өчен алынган кредитлар (заемнар) буенча:

төзелешнең титул исемлеге күчермәсе;

объектны төзүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә һәм (яки) модернизацияләүгә җыелма сметаның күчермәсе.

Эшләрне подряд алымы белән башкарганда:

технологик җиһазлар, башка эшләр өчен (проект эшләре, экспертиза, техник күзәтчелек) түләүне һәм эшләр башкару өчен подрядчыларга акча күчерүне, шул исәптән аванс түләүләре буенча) раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

технологик җиһазлар китерүгә, подряд эшләре, башка эшләр (проект эшләре, экспертиза, техник күзәтчелек) башкаруга шартнамәләрнең, төзелеш-монтаж эшләренең чыгымнары сметасы һәм башкару графигының заемга алучы һәм подрядчы тарафыннан расланган күчермәләре;

төзелеш материаллары, юридик һәм физик затларның эшләре һәм хезмәт күрсәтүләре өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

технологик җиһаз алуга товар-транспорт накладнойларының, счет-фактураларның күчермәләре;

җиһазны монтажга кабул итү-тапшыру актларының күчермәләре (№ ОС-15, формасы)*.

Заем алучы төзелеш материаллары өчен түләгәндә:

төзелеш материалларын китерү шартнамәләренең күчермәләре;

заем алучының төзелеш материалларын алуына товар-транспорт накладнойларының күчермәләре;

төзелеш материалларын аларның бәяләрен № КС-3* формасына кертү өчен подрядчыга тапшыру документларының күчермәләре;

башкарылган эшләрне кабул итү турында актларның заем алучы тарафыннан таныкланган күчермәләре (№ КС-2 формасы)*;

башкарылган эшләрнең бәясе һәм чыгымнар турында белешмәнең заемга алучы һәм подрядчы тарафыннан расланган күчермәсе (№ КС-3 формасы)*.

Эшләрне хуҗалык ысулы белән башкарганда:

төзелеш материаллары, юридик һәм физик затларның эшләре, хезмәт күрсәтүләре өчен өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

эшләрне хуҗалык ысулы белән башкару өчен җаваплы затларны һәм аның графигын билгеләү һәм эш күләме (мең сумнарда) турында боерыкның күчермәсе;

җыелма смета исәп-хисапларының һәм локаль сметаларның күчермәсе, эшләрне хуҗалык ысулы белән башкару турында боерык, башкарылган эшләр актларының күчермәләре (№ КС-2 формасы)*;

башкарылган эшләрнең бәясе һәм чыгымнар турында белешмәләр (№ КС-3 формасы)*;

технологик җиһазлар китерүгә, аерым эшләрне (проект эшләрен, экспертизаны, техник күзәтчелекне) подряд ысулы белән башкаруга шартнамәләрнең күчермәләре;

технологик җиһазлар өчен түләүне һәм подрядчыларга акча күчерүне, шул исәптән аванс түләүләре буенча, раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

Җиһазларны чит ил валютасына сатып алуны раслый торган документлар**:

импорт җиһазны сатып алу контрактының күчермәсе;

җиһаз өчен түләүгә аккредитив ачуны раслый торган түләү йөкләмәләренең һәм/яки документларының кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

товар китерүчегә валютаны күчерүне раслау турында дебет авизосының яки валютаны күчерү белән свифт хәбәренең күчермәләре;

йөк таможнясы декларациясенең күчермәсе (йөк таможнясы декларациясен законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә рәмиләштергәннән соң тапшырыла);

импорт алыш-бирешенең паспорты күчермәсе;

импорт алыш-биреше паспортының торышы турында белешмә;

җиһазны монтажга кабул итү-тапшыру актларының күчермәләре (№ ОС-15 формасы)*.

Крестьян (фермер) хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары өчен:

төзелешнең титул исемлеге күчермәсе;

объектларны төзүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә һәм (яки) модернизацияләүгә җыелма сметаның күчермәсе;

технологик җиһазлар китерүгә, подряд эшләрен, башка эшләрне (проект эшләрен, экспертизаны, техник күзәтчелекне) башкаруга шартнамәләрнең, төзелеш-монтаж эшләре башкару чыгымнары сметасының һәм аларны башкару графигының күчермәләре.

Эшләр графигы үтәлеп барган саен заем алучы тапшыра торган документлар:

подряд ысулы белән башкарыла торган эшләр, башка эшләр (проект эшләре, экспертиза, техник күзәтчелек) һәм технологик җиһаз өчен, аванс түләүләрен дә кертеп, төзелеш материаллары һәм эшләрне хуҗалык ысулы белән башкарганда читтәге оешмаларның хезмәт күрсәтүләре өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

башкарылган эшләр актларының күчермәләре;

бинаны (корылманы) файдалануга кабул итеп алу-тапшыру актларының күчермәләре (төзелеш тәмамланганнан соң тапшырыла, бу вакытта заем алучыларга субсидия эш этапларын үтәүгә карап түләнә).

Җиһазларны чит ил валютасына сатып алуны раслый торган документлар**:

импорт җиһазны сатып алу контрактының күчермәсе;

җиһаз өчен түләүгә аккредитив ачуны раслый торган түләү йөкләмәләренең һәм/яки документларының кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

валюта күчерүне раслау турында свифт хәбәренең күчермәләре;

йөк таможнясы декларациясенең күчермәсе (йөк таможнясы декларациясен законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә рәмиләштергәннән соң тапшырыла);

импорт алыш-бирешенең паспорты күчермәсе;

импорт алыш-биреше паспортының торышы турында белешмә;

бинаны (корылманы) кабул итү-тапшыру турында (№ ОС-1а формасы)* актларның һәм (яки) төп чараларның реконструкцияләнгән, модернизацияләнгән объектларын кабул итү-тапшыру турында (№ ОС-3 формасы)* актларының күчермәләре (төзелеш тәмамланганнан соң тапшырыла, бу вакытта заем алучыларга

субсидия эш этапларын үтәүгә карап түләнә).

Күпьеллык үсемлекләрне утыртканда:

утырту материаллары һәм (яки) шпалер кую өчен материаллар өчен, аванс түләүләрен дә кертеп, түләүне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

төп чараларны кабул итү – тапшыру турында (№ ОС-1 формасы)* актларының күчермәләре.

Утырту материалларын чит ил валютасына сатып алуны раслый торган документлар**:

импорт җиһазны сатып алу контрактының күчермәсе;

утырту материалын сатып алу контрактының кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәсе;

түләү йөкләмәләренең һәм (яки) утырту материалына түләү өчен аккредитив ачуны раслый торган документларның кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

валюта күчерүне раслау турында свифт хәбәренең күчермәләре;

йөк таможнясы декларациясенең күчермәсе (йөк таможнясы декларациясен контракт нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә рәмиләштергәннән соң тапшырыла);

импорт алыш-бирешенең паспорты күчермәсе;

импорт алыш-биреше паспортының торышы турында белешмә;

төп чараларны кабул итү- тапшыру турында (№ ОС-1 формасы)* актларының күчермәләре.

Искәрмә:

* № ОС-1а, № ОС-15, № КС-2, № КС-3, № ОС-1 формалары буенча субсидияне исәпләгәндә (максатчан кулланылышын раслау) суммалар максатчан куллануга НДС ны исәпкә алып кабул ителә.

**кредитны чит ил валютасында алган һәм аны сумнарда файдаланган очракта, инвестиция кредитының максатчан кулланылышын раслый торган документлар исемлеге сумнарда алынган инвестиция кредитының максатчан кулланылышын раслау өчен билгеләнгән документларның исемлегенә туры килә.

14. Идарә заем алучылар тапшырган документларны тикшерә, субсидияләрнең күләмен исәпләүләрне 2 көн эчендә килештерә һәм аларны заем алучыга кире кайтара.

15. Заем алучы Идарә тарафыннан килештерелгән, әлеге Тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгән документларны Министрлыкка агымдагы айның 1 нче числосыннан алып 20 нче числосына кадәр тапшыра.

Министрлык:

заем алучы гаризасын, гаризалар керү тәртибен саклап, журналга терки, ул номерлана, шнурлана һәм аңа Министрлык мөһере сугыла;

кабул ителгән документларны теркәгән көннән соң өч көн эчендә аларны карауга кабул итү турында яки аны кабул итүдән баш тарту турында, моның сәбәбен күрсәтеп, язма хәбәр сала;

заем алучы тарафыннан тапшырылган документларны 3 эш көне эчендә

тикшерә.

Заем алучыга субсидия бирүдә баш тартылса, Министрлык теркәү журналына тиешле язма кертә, заем алучыга исә ун көн эчендә тиешле язма хәбәрнамә юллана.

16. Документларны карауга алуда түбәндәге очракларда баш тартыла:

бюджет йөкләмәләре лимитлары булмаса;

тапшырылган документлар әлеге Тәртиптә каралган субсидияләрне бирү таләпләренә җавап бирмәсә.

Субсидияләр бирүдә түбәндәге очракларда баш тартыла:

бюджет йөкләмәләре лимитлары булмаса;

тапшырылган документлар әлеге Тәртиптә каралган субсидияләрне бирү таләпләренә җавап бирмәсә;

Субсидияләр бирүдән баш тартуга шикаять Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә агымдагы ел дәвамында бирелә.

тапшырылган документларда дөрес булмаган мәгълүмат булса.

17. Субсидияләрне күчерү Министрлыкның Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган хосусый счетыннан заем алучыларның исәп-хисап счетларына Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр күләме исәп-хисабына нигезләнеп 5 эш көне эчендә башкарыла.

18. Алынган субсидияләр аларны бирүнең әлеге Тәртиптә билгеләнгән максатлары һәм шартлары бозылу, субсидияләрне максатчан билгеләнеше буенча файдаланмау һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшыру очраклары ачыклану буенча Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән башлап алтмыш көн эчендә федераль бюджет керемнәренә кире кайтарылырга тиеш.

19. Субсидияләр бирү турында килешүләрдә каралган очракларда, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр федераль бюджет керемнәренә субсидияләр алучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

20. Күрсәтелгән акчаларны федераль бюджет керменә үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә кире кайтарылырга тиеш.

21. Министрлык һәм (яки) дәүләт финанс контроле органы заем алучыларга субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

22. Кредитларның һәм заемнарның максатчан тотылуын раслый торган, заем алучылар тарафыннан тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә аларга һәм аларның вазыйфаи затларына йөкләнә.

23. Бюджет акчаларының максатка ярашлы тотылуын Министрлык тикшереп тора.

2015 елның 17.08 194/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгына
3 нче кушымта

2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгына
9 нчы кушымта

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына 8 елга кадәр срокка алынган кредитлары һәм заемнары буенча процентлар түләү чыгымнарының бер олешен каплау очен 2015 елда субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип 8 елга кадәрге срокка Россия кредит оешмаларында һәм “Үсеш һәм тышкы икътисадый эшчәнлек банкы (Внешэкономбанк)” дәүләт корпорациясендә алынган кредитлар һәм авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативларында алынган заемнар буенча процентлар түләү чыгымнарының бер олешен каплау максатларында 2015 елда федераль бюджет акчалары исәбеннән субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына (хәзерләүче, тәэмин итүче, сатучы (сәүдә итүче), эшкәртүче, хезмәт күрсәтүче) һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына (алга таба – заем алучылар) бирелә.

3. Субсидияләр түбәндәгеләр тарафыннан алынган кредитлар (заемнар) буенча чыгымнарның бер өлешен каплауга бирелә:

а) шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга түбәндәге чорларда төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

2005 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 5 елга кадәр срокка – кечкенә габаритлы авыл хуҗалыгы техникасын, егәрлеге 100 ат көченә кадәр булган тракторларны һәм алар белән бергә агрегатлана торган авыл хуҗалыгы машиналарын, тулы массасы 3,5 тоннадан артмаган йөк ташучы автомобильләрне сатып алуга;

2005 елның 1 гыйнварыннан алып 5 елга кадәр срокка – шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданның агымдагы елда алынган кредитлары (заемнары) гомуми суммасы бер хуҗалыкка 700,0 мең сумнан артык булмаганда, авыл хуҗалыгы терлеген, терлекчелек һәм авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү җиһазларын сатып алуга, шулай ук терлекчелек биналарын ремонтлауга, реконструкцияләүгә һәм төзүгә, газ җиһазларын сатып алуга һәм газ челтәрләренә тоташуга;

2007 елның 1 гыйнварыннан алып 2 елга кадәр срокка – шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданның агымдагы елда алынган кредитлары (заемнары) гомуми суммасы бер хуҗалыкка 300,0 мең сумнан артык булмаганда, ягулык материаллары, авыл хуҗалыгы техникасын һәм терлекчелек биналарын ремонтлау

өчен запас частьләр һәм материаллар, минераль ашламалар, үсемлекләрне яклау чараларын, азыкларны, ветеринария препаратларын һәм сезонлы эшләр башкару өчен башка матди ресурсларны, шул исәптән теплицалар өчен материалларны, яшь авыл хуҗалыгы терлеген сатып алуга, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен иминләштергәндә иминият кертемнәрен түләүгә;

2008 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 5 елга кадәр срокка – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә авыл җирендә туристлыкны үстерү (авыл туризмы), халык кәсепләрен, авыл җирендә сәүдәне үстерүне дә кертеп, шулай ук халыкка көнкүреш һәм социаль-мәдәни хезмәт күрсәтү, кыргый җиләк-җимешләрне, дару үләннәрен һәм башка ашый торган һәм агач булмаган урман ресурсларын хәзерләү һәм эшкәртү белән бәйле юнәлешләрне үстерүгә;

2010 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 5 елга кадәр срокка – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә яңгыр яудыру һәм су сибү, насос станцияләре машиналарын, җайланмаларын һәм аппаратларын сатып алуга;

б) крестьян (фермер) хуҗалыклары тарафыннан түбәндәге чорларда төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

2005 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 8 елга кадәр срокка – авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазларын, шул исәптән терлекчелек, кошчылык, азык җитештерү өчен файдаланыла торган тракторларны һәм алар белән бергә агрегатлана торган авыл хуҗалыгы машиналарын, җиһазларын, яңгыр яудыру һәм су сибү, насос станцияләре машиналарын, җайланмаларын һәм аппаратларын, йөк автомобильләрен, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын газ ягулыгына күчерү өчен җиһазлар сатып алуга;

2005 елның 1 гыйнварыннан алып 8 елга кадәр срокка – агымдагы елда алынган кредитлары (заемнары) гомуми суммасы бер хуҗалыкка 10,0 миллион сумнан артык булмаганда, авыл хуҗалыгы продукциясен саклауга һәм эшкәртүгә, нәселле авыл хуҗалыгы терлеген, нәселлек продукциясен (материалын), бәрәңге базларын, яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр саклау урыннарын, ябык грунтта җиләк-җимеш, яшелчә продукциясен җитештерү буенча теплица комплексларын, җитенне һәм җитен сүсен эшкәртү объектларын, авыл хуҗалыгы үсемлекләренең орлыкларын хәзерләү комплексларын, терлекчелек комплексларын (фермаларын), терлекчелек, азык җитештерү объектларын, күпьеллык үсемлекләр өчен ялгау комплексларын төзүгә, реконструкцияләүгә, күпьеллык үсемлекләр һәм виноградлыклар утыртуга;

2007 елның 1 гыйнварыннан алып 2 елга кадәр срокка – агымдагы елда алынган кредитлары (заемнары) гомуми суммасы бер хуҗалыкка 5,0 миллион сумнан артык булмаганда, ягулык материаллары, авыл хуҗалыгы техникасын һәм терлекчелек биналарын ремонтлау өчен запас частьләр һәм материаллар, минераль ашламалар, үсемлекләрне яклау чараларын, азыкларны, ветеринария

препаратларын һәм сезонлы эшләр башкару өчен башка матди ресурсларны, шул исәптән теплицалар өчен материалларны, яшь авыл хуҗалыгы терлеген сатып алуга, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен иминләштергәндә иминият кертемнәрен түләүгә;

2008 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 5 елга кадәр срокка – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә авыл җирендә туристлыкны үстерү (авыл туризмы), халык кәсепләрен, авыл җирендә сәүдәне үстерүне дә кертеп, шулай ук халыкка көнкүреш һәм социаль-мәдәни хезмәт күрсәтү, кыргый җиләк-җимешләрне, дару үләннәрен һәм башка ашарга яраклы һәм агач булмаган урман ресурсларын хәзерләү һәм эшкәртү белән бәйле юнәлешләрне үстерүгә;

в) авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары тарафыннан түбәндәге чорларда төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча:

2005 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 8 елга кадәр срокка – авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазларын (Россиядә һәм чит илдә җитештерелгән), шул исәптән катнаш азыкны, инкубация йомыркаларын, нәселле яшь терлекне һәм кош-кортларны ташу өчен махсуслаштырылган транспортка, терлекчелек, кошчылык, азык җитештерү өчен файдаланыла торган тракторларны һәм алар белән бергә агрегатлана торган авыл хуҗалыгы машиналарын, җиһазларын, йөк автомобильләрен, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын газ ягулыгына күчерү өчен җиһазлар сатып алуга;

2005 елның 1 гыйнварыннан алып 8 елга кадәр срокка – агымдагы елда алынган кредитлары (заемнары) гомуми суммасы бер кооперативка 40,0 миллион сумнан артык булмаганда, махсуслаштырылган технологик җиһазлар, суыткычлар, авыл хуҗалыгы терлеген, нәселлек продукциясен (материалын) сатып алуга, бәрәңге базларын, яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр саклау урыннарын, ябык грунтта җиләк-җимеш, яшелчә продукциясен җитештерү буенча теплица комплексларын, җитенне һәм җитен сүсен эшкәртү объектларын, авыл хуҗалыгы базарларын, сату мәйданнарын, сөт, ит, яшелчә, җиләк-җимеш һәм башка авыл хуҗалыгы продукциясен кабул итү, беренчел эшкәртү һәм саклау пунктларын төзүгә, реконструкцияләүгә, шулай ук күпьеллык үсемлекләр һәм виноградлыклар утыртуга, күпьеллык үсемлекләр өчен ялгау комплекларын төзүне һәм реконструкцияләүне дә кертеп;

2007 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 2 елга кадәр срокка – авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазларын ремонтлау өчен запас частьләр һәм материаллар сатып алуга, шул исәптән аларны кооператив әгъзаларына китерүгә;

2007 елның 1 гыйнварыннан алып 2 елга кадәр срокка – агымдагы елда алынган кредитлары (заемнары) гомуми суммасы бер кооперативка 15,0 миллион сумнан артык булмаганда, сезонлы эшләр башкару өчен башка матди ресурсларны, яшь авыл хуҗалыгы терлеген сатып алуга, беренчел һәм сәнәгать эшкәртүе өчен үзебездәге авыл хуҗалыгы чималын (2013 елдан башлап - беренчел һәм сәнәгать эшкәртүе өчен үзебездәге авыл хуҗалыгы чималын), кооператив әгъзалары

тарафыннан алга таба сату өчен җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен сатып алуга, шулай ук кооперативны оештырылу ягыннан төзекләндерүгә һәм авыл хуҗалыгы продукциясен иминләштергәндә иминият кертемнәрен түләүгә;

2008 елның 1 гыйнварыннан алып 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, 5 елга кадәр срокка – Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә авыл җирендә туристлыкны үстерү (авыл туризмы), халык кәсепләрен, авыл җирендә сәүдәне үстерүне дә кертеп, шулай ук халыкка конкүреш һәм социаль-мәдәни хезмәт күрсәтү, кыргый җиләк-җимешләрне, дару үләннәрен һәм башка ашый торган һәм агач булмаган урман ресурсларын хәзерләү һәм эшкәртү белән бәйле юнәлешләрне үстерүгә;

г) әлеге пунктның “а” - “в” пунктчаларында каралган кредитларны (заемнарны) рефинанслауга алынган кредитлар (заемнар) буенча, кредитлардан (заемнардан) файдалануның бергә кушылган сроклары әлеге пунктчаларда күрсәтелгән сроклардан артып китмәсә.

4. 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча кредитлардан (заемнардан) файдалану срокларын озайту турында килешү имзаланган очракта:

әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы “а” пунктчасының икенче һәм өченче абзацларында каралган 2005 елның 1 гыйнварыннан төзелгән кредитлар (заемнар) буенча чыгымнарның бер өлешен каплау мондый шартнамәләрнең срогын 2 елдан артмаган вакытка озайтып башкарыла;

әлеге Тәртипнең 3 пунктындагы “а” пунктчасының дүртенче абзацында каралган кредитлар (заемнар) буенча чыгымнарның бер өлешен каплау мондый шартнамәләрнең срогын 1 елдан артмаган вакытка озайтып башкарыла;

авыл хуҗалыгы продукцияләренә 2010 елгы корылык зыян китергән авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары һәм крестьян (фермер) хуҗалыклары тарафыннан әлеге Тәртипнең 3 пунктчасында каралган һәм 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча чыгымнарның бер өлешен каплау мондый шартнамәләрнең срогын 3 елдан артмаган вакытка озайтып башкарыла.

5. Заем алучыларга чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр аларның төп бурычны һәм исәпләнгән процентларны түләү, кредитны (заемны) максатчан билгеләнешендә файдалану йөкләмәләре үтәлгән очракта бирелә.

Төп бурычны каплау һәм исәпләнгән процентларны түләү йөкләмәләре бозылу аркасында исәпләнгән һәм түләнгән процентларны түләүгә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирелми.

6. Заем алучыларга процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау түбәндәгечә башкарыла:

а) 2012 елның 31 декабренә кадәр, шул көнне дә кертеп, төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган кредитлар (заемнар) буенча - кредит шартнамәсен (заем шартнамәсен) төзегән көндә гамәлдә булган Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау

ставкасының (исәп ставкасы) 95 проценты күләмендә,

б) 2013 елның 1 гыйнварыннан башлап төзелгән кредит шартнамәләре (заем шартнамәләре) буенча әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган кредитлар (заемнар) буенча - Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәп ставкасы) очтән ике өлеше күләмендә;

в) әлеге Тәртипнең 3 пунктында каралган кредитлар (заемнар) буенча 2015 ел очен процентлар (вакытыннан алда түләнгән процентларны да кертеп) түләү чыгымнарының бер олешен кайтаруга - Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасының (исәп ставкасы) 100 проценты күләмендә.

7. Субсидияләрнең күләмен исәпләү, максатчан билгеләнешендә кулланылган кредит (заем) суммасыннан чыгып, кредит шартнамәсен (заем шартнамәсен) төзегән конгә, ә кредит шартнамәсенә (заем шартнамәсенә) кредиттан (заемнан) файдаланган өчен түләү арту белән бәйле өстәмә килешү төзелгән очракта – кредит шартнамәсенә (заем шартнамәсенә) өстәмә килешү төзегән көнгә гамәлдә булган Россия Федерациясе Үзәк банкының рефинанслау ставкасы буенча башкарыла.

8. Заем алучыга чыгымнарының бер олешен каплау өчен бирелә торган субсидиянең күләме заем алучының мондый кредиты (заемы) буенча фактагы процентлар түләү чыгымнарыннан күбрәк булырга тиеш түгел.

9. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба – Идарә) заем алучыдан түбәндәге документларны кабул итеп ала:

а) шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнар алган кредитлар (заемнар) буенча:

түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

кредит шартнамәсенең (заем шартнамәсенең) кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләрен, кредит (заем) алу турында ссуда счетыннан өземтәне, түләп бетерү һәм аның буенча процентлар түләү гарфигын;

Министрлык раслаган форма буенча субсидияләр күләме исәп-хисабын;

шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданның шәхси ярдәмче хуҗалыгын теркәү турында хуҗалык кенәгәсеннән өземтәне;

әлеге Боерыкның 10 пунктында каралган исемлек буенча кредитның (заемның) максатчан билгеләнешендә кулланылуын раслый торган документларның башкарма комитет тарафыннан таныкланган күчермәләрен – кредиттан файдалану дәрәҗәсенә карап.

б) крестьян (фермер) хуҗалыклары алган кредитлар (заемнар) буенча:

түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

кредит шартнамәсенең (заем шартнамәсенең) кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләрен, кредит (заем) алу турында ссуда счетыннан өземтәне, түләп бетерү һәм аның буенча процентлар түләү гарфигын;

әлеге Боерыкның 11 пунктында каралган исемлек буенча кредитның

(заемның) максатчан билгеләнешендә кулланылуын раслый торган документларның заем алучы тарафыннан таныкланган күчермәләрен –кредиттан файдалану дәрәҗәсенә карап.

в) авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары алган кредитлар (заемнар) буенча:

түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны;

кредит шартнамәсенең (заем шартнамәсенең) кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләрен, кредит (заем) алу турында ссуда счетыннан өземтәне, түләп бетерү һәм аның буенча процентлар түләү графигын;

әлеге Боерыкның 11 пунктында каралган исемлек буенча кредитның (заемның) максатчан билгеләнешендә кулланылуын раслый торган документларның заем алучы тарафыннан таныкланган күчермәләрен – кредиттан файдалану дәрәҗәсенә карап.

10. Кредитның (заемның) максатчан билгеләнешендә кулланылуын раслый торган документларның башкарма комитет тарафыннан таныкланган күчермәләре, кредиттан файдалану дәрәҗәсенә карап:

кечкенә габаритлы авыл хуҗалыгы техникасын, егәрлеге 100 ат көченә кадәр булган тракторларны һәм алар белән бергә агрегатлана торган авыл хуҗалыгы машиналарын, тулы массасы 3,5 тоннадан артмаган йок ташучы автомобильләрне сатып алу өчен алынган кредитлар (заемнар) буенча:

кечкенә габаритлы авыл хуҗалыгы техникасын, йөк ташучы автомобильләрне, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын һәм җиһазларын оешмаларда, ваклап сату җирләрендә яки индивидуаль эшкуарлардан сатып алганда тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән сату-алу шартнамәләренең яки накладнойларының яки товар чекларының, шулай ук түләү йөкләмәләренең яки касса чекларының яки приход касса ордерларының төп нөсхәләре, күчермәләре; кечкенә габаритлы авыл хуҗалыгы техникасын, йөк ташучы автомобильләрне, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын һәм җиһазларын физик затлардан акчалата исәп-хисап белән сатып алганда заем алучыдан акчалар алу күрсәтелгән сату-алу шартнамәләренең һәм сатучылар (товар китерүчеләр) биргән расписканың төп нөсхәләре, күчермәләре;

транспорт чараларын сатып алганда билгеләнгән тәртиптә исәпкә куелу турында тамга булган транспорт чаралары паспортларының төп нөсхәләре, күчермәләре;

муниципаль берәмлекнең – шәһәр һәм авыл җирлекләренең – башкарма комитетыннан (алга таба – башкарма комитет) хуҗалык кенәгәләреннән белешмә-өземтәләр;

шәхси ярдәмче хуҗалык тарафыннан алынган кредитның максатчан тотылуын тикшерү турында башкарма комитет тарафыннан төзелгән акт.

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданның агымдагы елда алынган кредитлары (заемнары) гомуми суммасы бер хуҗалыкка 700 мең сумнан артык булмаганда, авыл хуҗалыгы терлеген, терлекчелек һәм авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү җиһазларын сатып алу, шулай ук терлекчелек биналарын

ремонтлау, реконструкцияләү һәм төзү, газ җиһазларын сатып алу һәм газ челтәрләренә тоташтыру өчен алынган кредитлар (заемнар) буенча:

авыл хуҗалыгы терлеген сатып алганда тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән сату-алу шартнамәләренең яки накладнойларының яки товар чекларының, шулай ук түләү йөкләмәләренең яки касса чекларының яки приход касса ордерларының төп нөсхәләре, күчермәләре;

авыл хуҗалыгы терлеген физик затлардан акчалата исәп-хисап белән сатып алганда заем алучыдан акчалар алу күрсәтелгән сату-алу шартнамәләренең һәм сатучылар (товар китерүчеләр) биргән распискаларның төп нөсхәләре, күчермәләре;

сатып алганда авыл хуҗалыгы терлегенең хәрәкәте турында башкарма комитетның хуҗалык кенәгәләреннән белешмә-өземтәләр;

төзелә яки реконструкцияләнә торган терлекчелек биналарының, аларның зурлыклары һәм кулланыла торган материалларны күрсәтеп, заем алучы тарафыннан имзаланган схемасы;

заем алучы тарафыннан төзелгән һәм имзаланган, башкарма комитет тарафыннан расланган чыгымнар сметасы (җыелмасы), чыгымнар сметасына (җыелмасына) ярашлы рәвештә билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән касса чекларының яки приход касса ордерларының, сатып алынган материалларга товар накладнойларының яки товар чекларының төп нөсхәләре, күчермәләре;

терлекчелек биналарын реконструкцияләү, модернизацияләү һәм төзү эшләрен башкаруга (подряд ысулы белән) шартнамәләрнең, терлекчелек биналарын реконструкцияләгәндә, модернизацияләгәндә һәм төзегәндә башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган башкарылган эшләр актларының һәм түләү документларының төп нөсхәләре, күчермәләре;

җиһазларны алу накладнойларының (товар чекларының) һәм газ җиһазлары, материаллары өчен түләүне раслый торган түләү документларының төп нөсхәләре, күчермәләре;

газ челтәрләренә тоташтырганда башкарылган эшләр актларының һәм башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган түләү документларының төп нөсхәләре, күчермәләре;

шәхси ярдәмче хуҗалык тарафыннан алынган кредитның максатчан тотылуын тикшерү турында акт.

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданның агымдагы елда алынган кредитлары (заемнары) гомуми суммасы бер хуҗалыкка 300 мең сумнан артык булмаганда, ягулык материаллары, авыл хуҗалыгы техникасын һәм терлекчелек биналарын ремонтлау өчен запас частьләр һәм материаллар, минераль ашламалар, үсемлекләрне яклау чараларын, азыкларны, ветеринария препаратларын һәм сезонлы эшләр башкару өчен башка матди ресурсларны, шул исәптән теплицалар өчен материалларны, яшь авыл хуҗалыгы терлеген сатып алуга, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен иминләштергәндә иминият кертемнәрен түләүгә:

матди ресурсларны юридик затлардан яки индивидуаль эшкуарлардан сатып алганда, тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән сату-алу шартнамәләренең яки накладнойларының яки товар чекларының, шулай ук түләү йөкләмәләренең яки

касса чекларының яки приход касса ордерларының топ нөсхәләре, күчермәләре;

авыл хуҗалыгы яшь терлеген һәм азыкны физик затлардан сатып алганда акчалата исәп-хисап белән сатып алганда заем алучыдан акчалар алу күрсәтелгән сату-алу шартнамәләренең һәм сатучылар (товар китерүчеләр) биргән расписикаларның топ нөсхәләре, күчермәләре;

иминләштерү шартнамәләренең һәм иминият кертемнәрен түләүгә түләү документларының төп нөсхәләре, күчермәләре;

матди товар кыйммәтләр һәм төп чаралар заем алучы белән бергә яшәми торган һәм (яки) аның белән бергә шәхси ярдәмче хуҗалыкны алып бармый торган физик затлардан сатып алынырга тиеш. Әгәр заем алучы шәхси ярдәмче хуҗалыкны алып баручы граждан яки заем алучы белән бергә яшәүче һәм (яки) аның белән бергә шәхси ярдәмче хуҗалыкны алып баручы  физик зат булса, бер үк вакытта алар индивидуаль эшкуарлар булып торсалар, матди товар кыйммәтләр һәм төп чараларны сатып алу башка индивидуаль эшкуарлар белән башкарылырга тиеш;

башкарма комитеттан хуҗалык кенәгәләреннән белешмә-өземтәләр;

шәхси ярдәмче хуҗалык тарафыннан алынган кредитның максатчан тотылуын тикшерү турында акт.

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә авыл җирендә туристлыкны үстерү (авыл туризмы), халык кәсепләрен, авыл җирендә сәүдәне үстерүне дә кертеп, шулай ук халыкка көнкүреш һәм социаль-мәдәни хезмәт күрсәтү, кыргый җиләк-җимешләрне, дару үләннәрен һәм башка ашый торган һәм агач булмаган урман ресурсларын хәзерләү һәм эшкәртү белән бәйле юнәлешләрне үстерүгә:

заем алучы тарафыннан төзелгән һәм имзаланган, башкарма комитет тарафыннан расланган чыгымнар сметасы (җыелмасы);

чыгымнар сметасына (җыелмасына) ярашлы рәвештә билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән касса чекларының яки приход касса ордерларының, сатып алынган материалларга товар накладнойларының яки товар чекларының төп нөсхәләре, күчермәләре;

объектларны реконструкцияләү, модернизацияләү һәм төзү эшләрен башкаруга (подряд ысулы белән) шартнамәләрнең, объектларны реконструкцияләгәндә, модернизацияләгәндә һәм төзегәндә башкарылган  эшләр өчен түләүне раслый торган башкарылган эшләр актларының һәм түләү документларының төп нөсхәләре, күчермәләре;

башкарма комитеттан хуҗалык кенәгәләреннән белешмә-өземтәләр;

шәхси ярдәмче хуҗалык тарафыннан алынган кредитның максатчан тотылуын тикшерү турында акт.

11. Кредитның (заемның) максатчан билгеләнешендә кулланылуын раслый торган документларның заем алучы тарафыннан таныкланган күчермәләре, кредиттан файдалану дәрәҗәсенә карап:

Авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазларын, шул исәптән терлекчелек, кошчылык, азык җитештерү өчен файдаланыла торган  тракторларны һәм алар белән бергә агрегатлана торган авыл хуҗалыгы машиналарын, җиһазларын, яңгыр

яудыру һәм су сибү, насос станцияләре машиналарын, җайланмаларын һәм аппаратларын, йөк автомобильләрен, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын газ ягулыгына күчерү өчен җиһазлар сатып алуга алынган кредитлар (заемнар) буенча:

авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазларын сатып алу (лизингка) шартнамәләренең күчермәләре;

авыл хуҗалыгы техникасы һәм җиһазлар өчен түләүнераслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазларын сатып алуга товар-транспорт накладнойларының, счет-фактураларының күчермәләре;

транспорт чараларын сатып алганда тиешле тәртиптә исәпкә куелу турында тамга сугылган транспорт чаралары паспортларының күчермәләре.

Авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазларын чит ил валютасына сатып алуны раслый торган документлар:

импорт авыл хуҗалыгы техникасын һәм җиһазын сатып алу контрактының күчермәсе;

авыл хуҗалыгы техникасы һәм җиһазы өчен түләүгә аккредитив ачуны раслый торган түләү йөкләмәләренең һәм (яки) документларының кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

валюта күчерүне раслау турында свифт хәбәрләрнең заем алучы тарафыннан расланган күчермәләре;

йөк таможнясы декларациясенең күчермәсе (йөк таможнясы декларациясен законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә рәмиләштергәннән соң тапшырыла);

импорт алыш-бирешенең паспорты күчермәсе;

импорт алыш-биреше паспортының торышы турында белешмә;

транспорт чараларын сатып алганда тиешле тәртиптә исәпкә куелу турында тамга сугылган транспорт чаралары паспортларының күчермәләре.

Агымдагы елда алынган кредитның (заемның) гомуми суммасы бер хуҗалыкка 10 миллион сумнан артык булмаганда, авыл хуҗалыгы продукциясен саклауга һәм эшкәртүгә, нәселле авыл хуҗалыгы терлеген, нәселлек продукциясен (материалын), бәрәңге базларын, яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр саклау урыннарын, ябык грунтта җиләк-җимеш, яшелчә продукциясен җитештерү буенча теплица комплексларын, җитенне һәм җитен сүсен эшкәртү объектларын, авыл хуҗалыгы үсемлекләренең орлыкларын хәзерләү комплексларын, терлекчелек комплексларын (фермаларын), терлекчелек, азык җитештерү объектларын күпьеллык үсемлекләр өчен ялгау комплекларын төзүгә, реконструкцияләүгә, күпьеллык үсемлекләр һәм виноградлыклар утыртуга алынган кредитлар (заемнар) буенча:

нәселле авыл хуҗалыгы терлеген, нәселле продукцияне (материалны) сатып алу (лизингка) шартнамәләренең күчермәләре;

нәселле авыл хуҗалыгы терлеге, нәселле продукция (материал) өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

нәселле авыл хуҗалыгы терлеген, нәселле продукцияне (материалны) кабул итү-тапшыру актларының күчермәләре;

нәселле авыл хуҗалыгы терлеген, нәселле продукцияне (материалны) сатып алуга нәсел таныклыкларының күчермәләре.

Нәселле авыл хуҗалыгы терелеген, нәселле продукцияне (материалны) чит ил валютасына сатып алуны раслый торган документлар:

нәселле авыл хуҗалыгы терлеген, нәселле продукцияне (материалны) сатып алу контрактының күчермәсе;

нәселле авыл хуҗалыгы терлеге, нәселле продукция (материал) очен түләүгә аккредитив ачуны раслый торган түләү йөкләмәләренең һәм (яки) документларының кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

валюта күчерүне раслау турында свифт хәбәрләрнең күчермәләре;

йөк таможнясы декларациясенең күчермәсе (йөк таможнясы декларациясен законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә рәмиләштергәннән соң тапшырыла);

импорт алыш-бирешенең паспорты күчермәсе;

импорт алыш-биреше паспортының торышы турында белешмә;

нәселле авыл хуҗалыгы терлегенең, нәселле продукциянең (материалның) нәселлек ягыннан кыйммәтен раслый торган документларның күчермәләре;

төзелешнең титул исемлеге күчермәсе;

объектларны төзүгә, реконструкцияләүгә һәм модернизацияләүгә җыелма сметаның күчермәсе.

Эшләрне подряд алымы белән башкарганда:

технологик җиһазлар, подряд ысулы белән башкарылган эшләр, аванс түләүләрен дә кертеп, төзелеш материаллары һәм эшләрне хуҗалык ысулы белән алып барганда чит оешмаларның хезмәт күрсәтүе өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

башкарылган эшләр актларының күчермәләре;

бинаны (корылманы) файдалануга кабул итү-тапшыру актларының күчермәләре (төзелеш беткәннән соң тапшырыла, бу вакытта субсидия эшләрнең башкарылуына карап бирелә).

Күпьеллык үсемлекләрне һәм виноградлыкларны утыртканда:

утырту материаллары һәм шпалерлар кую өчен каралган материаллар өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

утыртуны кабул итү актларының күчермәләре (эшләр төгәлләнгәннән соң).

Утырту материалын чит ил валютасына сатып алуны раслый торган документлар:

утырту материалын сатып алу контрактының күчермәсе;

утырту материалы өчен түләүгә аккредитив ачуны раслый торган түләү йөкләмәләренең һәм (яки) документларының кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

валютаны күчерүне раслау турында свифт хәбәрләрнең күчермәләре;

йөк таможнясы декларациясенең күчермәсе (йөк таможнясы декларациясен

законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә рәмиләштергәннән соң тапшырыла);

импорт алыш-бирешенең паспорты күчермәсе;

импорт алыш-биреше паспортының торышы турында белешмә;

утыртуны кабул итү актларының күчермәләре (эшләр тогәлләнгәннән соң).

Агымдагы елда алынган кредитның (заемның) гомуми суммасы бер хуҗалыкка 5 миллион сумнан артык булмаганда, ягулык материаллары, авыл хуҗалыгы техникасын һәм терлекчелек биналарын ремонтлау өчен запас частьләр һәм материаллар, минераль ашламалар, үсемлекләрне яклау чараларын, азыкларны, ветеринария препаратларын һәм сезонлы эшләр башкару өчен башка матди ресурсларны, шул исәптән теплицалар өчен материалларны, яшь авыл хуҗалыгы терлеген сатып алуга, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен иминләштергәндә иминият кертемнәрен түләүгә:

сезонлы эшләр башкару өчен матди ресурслар, яшь авыл хуҗалыгы терлеген сатып алу шартнамәләренең күчермәләре түләү йөкләмәсендә түләү өчен нигез буларак “түләү билгеләнеше” юлында күрсәтелгән очракта тапшырылалар;

азык, ягулык-май материалларын һәм запас частьләрне сатып алганда түләү йөкләмәләренең яки касса чекларының яки приход касса ордерларының (юридик затлардан яки индивидуаль эшкуарлардан сатып алганда) кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре, шулай ук сатып алына торган башка матди ресурсларның түләү йөкләмәләренең күчермәләре;

накладнойларының яки товар чекларының күчермәләре.

авыл хуҗалыгы продукциясен иминләштерүгә:

иминләштерү шартнамәсенең күчермәсе;

иминият кертемнәрен түләү өчен түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә авыл җирендә туристлыкны үстерү (авыл туризмы), халык кәсепләрен, авыл җирендә сәүдәне үстерүне дә кертеп, шулай ук халыкка көнкүреш һәм социаль-мәдәни хезмәт күрсәтү, кыргый җиләк-җимешләрне, дару үләннәрен һәм башка ашый торган һәм агач булмаган урман ресурсларын хәзерләү һәм эшкәртү белән бәйле юнәлешләрне үстерүгә алынган кредитлар (заемнар) буенча:

төзелешнең титул исемлеге күчермәсе;

объектны төзүгә, реконструкцияләүгә һәм ремонтлауга җыелма сметаның күчермәсе.

технологик җиһазлар китерүгә, подряд эшләрен, башка эшләрне (проект эшләрен, экспертизаны, техник күзәтчелекне) башкаруга шартнамәләрнең, төзелеш-монтаж эшләрен башкару графигының күчермәләре;

Эшләр графигы үтәлеп барганда заем алучы тапшыра торган документлар:

технологик җиһаз һәм подряд ысулы белән башкарылган эшләр, башка эшләр (проект эшләре, экспертиза, техник күзәтчелек) өчен, аванс түләүләрен дә кертеп, төзелеш материаллары һәм хуҗалык ысулы белән эшләр башкарганда чит оешмаларның хезмәт күрсәтүләре өчен түләүне раслый торган түләү

йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

башкарылган эшләр актларның күчермәләре;

бинаны (корылманы) файдалануга кабул итеп алу – тапшыру актларының күчермәләре (төзелеш тәмамланганнан соң тапшырыла, бу вакытта заем алучыларга субсидия эш этапларын үтәүгә карап түләнә).

Транспорт чараларын, техниканы һәм җиһазларны чит ил валютасына сатып алуны раслый торган документлар:

сатып алу контрактының күчермәсе;

түләүгә аккредитив ачуны раслый торган түләү йөкләмәләренең һәм/яки документларының кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

валютаны күчерүне раслау турында свифт хәбәрләрнең күчермәләре;

йөк таможнясы декларациясенең күчермәсе (йөк таможнясы декларациясен законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә рәмиләштергәннән соң тапшырыла);

импорт алыш-бирешенең паспорты күчермәсе;

импорт алыш-биреше паспортының торышы турында белешмә;

транспорт чараларын сатып алганда тиешле тәртиптә исәпкә куелу турында тамга сугылган транспорт чаралары паспортларының күчермәләрен.

Кирәкле җиһазларны, матди ресурсларны, транспорт чараларын һәм инвентарне сатып алуга алынган кредитлар (заемнар) буенча:

җиһазларны оешмаларда, ваклап сату җирләрендә яки индивидуаль эшкуарлардан сатып алганда тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән сату-алу шартнамәләренең яки накладнойларының яки товар чекларының, шулай ук түләү йөкләмәләренең яки касса чекларының яки приход касса ордерларының төп нөсхәләре, күчермәләре, шулай ук транспорт чараларын сатып алган вакытта билгеләнгән тәртиптә исәпкә куелуы турында билге салынган транспорт чаралары паспортларының күчермәләре.

Кыргый җиләк-җимешләрне, дару үләннәрен һәм башка ашарга яраклы һәм агач булмаган урман ресурсларын (алга таба – кыргый ресурслар) сатып алганда:

оешмаларда, ваклап сату җирләрендә яки индивидуаль эшкуарлардан сатып алганда, кыргый ресурсларны сатып алу шартнамәләренең заем алучы тарафыннан таныкланган күчермәләре, кыргый ресурслар өчен түләү йөкләмәләренең күчермәләре;

физик затлардан сатып алганда, билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән сатып алу актларының күчермәләре яки сатып алынган кыргый ресурслар өчен түләүне раслый торган накладнойларның һәм документларның күчермәләре;

кредит шартнамәсенең (заем шартнамәсенең) гамәлдә булу чорында рәсмиләштерелгән авыл хуҗалыгына карамаган тиешле эшчәнлек төрләрен башкаруны раслый торган башка документлар.

Техниканы һәм җиһазларны (Россиядә һәм чит илдә җитештерелгән), шул исәптән катнаш азыкны, инкубация йомыркаларын, чебиләрне, нәселле яшь терлекне һәм кош-кортларны ташу өчен махсуслаштырылган транспортка, терлекчелек, кошчылык, азык җитештерү өчен файдаланыла торган тракторларны һәм алар белән бергә агрегатлана торган авыл хуҗалыгы машиналарын,

җиһазларын, йөк автомобильләрен, тракторларны һәм авыл хуҗалыгы машиналарын газ ягулыгына күчерү өчен җиһазлар сатып алуга алынган кредитлар (заемнар) буенча:

техниканы һәм җиһазларны сатып алу (лизингка) шартнамәләренең күчермәләре;

техника һәм җиһазлар өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

техниканы һәм җиһазларны сатып алуга товар-транспорт накладнойларының, счет-фактураларының күчермәләре;

транспорт чараларын сатып алганда тиешле тәртиптә исәпкә куелу турында тамга сугылган транспорт чаралары паспортларының күчермәләре.

Техниканы һәм җиһазларны чит ил валютасына сатып алуны раслый торган документлар:

импорт техниканы һәм җиһазны сатып алу контрактының күчермәсе;

техника һәм җиһаз өчен түләүгә аккредитив ачуны раслый торган түләү йөкләмәләренең һәм (яки) документларының кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

валютаны күчерүне раслау турында свифт хәбәрләрнең күчермәләре;

йөк таможнясы декларациясенең күчермәсе (йөк таможнясы декларациясен законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә рәмиләштергәннән соң тапшырыла);

импорт алыш-бирешенең паспорты күчермәсе;

импорт алыш-биреше паспортының торышы турында белешмә;

транспорт чараларын сатып алганда тиешле тәртиптә исәпкә куелу турында тамга сугылган транспорт чаралары паспортларының күчермәләре.

Агымдагы елда алынган кредитның (заемның) гомуми суммасы бер кооперативка 40 миллион сумнан артык булмаганда, махсуслаштырылган технологик җиһазлар, суыткычлар, авыл хуҗалыгы терлеген, нәселлек продукциясен (материалын) сатып алуга, шул исәптән аларны кооператив әгъзаларына китерү өчен, бәрәңге базларын, яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр саклау урыннарын, ябык грунтта җиләк-җимеш, яшелчә продукциясен җитештерү буенча теплица комплексларын, терлекчелек, азык җитештерү объектларын, җитенне һәм җитен сүсен эшкәртү объектларын, авыл хуҗалыгы базарларын, сату мәйданнарын, сөт, ит, яшелчә, җиләк-җимеш һәм башка авыл хуҗалыгы продукциясен кабул итү, беренчел эшкәртү һәм саклау пунктларын төзүгә, реконструкцияләүгә, шулай ук күпьеллык үсемлекләр һәм виноградлыклар утыртуга алынган, күпьеллык үсемлекләр өчен ялгау комплекларын төзүне һәм реконструкцияләүне дә кертеп, кредитлар (заемнар) буенча:

төзелешнең титул исемлеге күчермәсе;

объектларны төзүгә һәм (яки) реконструкцияләүгә һәм (яки) модернизацияләүгә җыелма сметаның күчермәсе;

технологик җиһазлар китерүгә, подряд эшләрен башкаруга шартнамәләрнең, төзелеш-монтаж эшләре башкару графигының күчермәләре.

Эшләр графигы үтәлеп барганда заем алучы тапшыра торган документлар:

технологик җиһаз һәм подряд ысулы белән башкарылган эшләр очен түләүне, аванс түләүләрен дә кертеп, төзелеш материаллары һәм эшләрне хуҗалык ысулы белән башкарганда чит оешмаларның хезмәт күрсәтүләре өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

заем алучы тарафыннан расланган башкарылган эшләр актларның күчермәләре;

бинаны (корылманы) файдалануга кабул итеп алу – тапшыру актларының күчермәләре (төзелеш тәмамланганнан соң тапшырыла, бу вакытта заем алучыларга субсидия эш этапларын үтәүгә карап түләнә);

Күпьеллык үсемлекләрне һәм виноградлыкларны утырту өчен алынган кредитлар (заемнар) буенча:

утырту материаллары һәм (яки) шпалерлар кую өчен каралган материаллар өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

утыртуны кабул итү актларының заем алучы тарафыннан расланган күчермәләре (эшләр төгәлләнгәннән соң);

Утырту материалын чит ил валютасына сатып алуны раслый торган документлар:

утырту материалын сатып алу шартнамәсенең заем алучы тарафыннан расланган күчермәсе;

түләү йөкләмәләренең һәм (яки) утырту материалы өчен түләүгә аккредитив ачуны раслый торган документларның кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

валюта күчерүнераслау турында свифт хәбәрләрнең күчермәләре;

йөк таможнясы декларациясенең күчермәсе (йөк таможнясы декларациясен законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә рәмиләштергәннән соң тапшырыла);

импорт алыш-бирешенең паспорты күчермәсе;

импорт алыш-биреше паспортының торышы турында белешмә;

утыртуны кабул итү актларының күчермәләре (эшләр төгәлләнгәннән соң).

Авыл хуҗалыгы терлеген, нәселле продукцияне (материалны) сатып алу өчен алынган кредитлар (заемнар) буенча:

авыл хуҗалыгы терлеген, нәселле продукцияне (материалны) сатып алу (лизингка) шартнамәсенең күчермәсе;

авыл хуҗалыгы терлеге, нәселле продукция (материал) өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

авыл хуҗалыгы терлеген, нәселле продукцияне (материалны) кабул итү – тапшыру актларының күчермәләре;

авыл хуҗалыгы терлеген, нәселле продукцияне (материалны) сатып алуга нәсел таныклыкларының күчермәләре.

Авыл хуҗалыгы терлеген, нәселле продукцияне (материалны) чит ил валютасына сатып алуны раслый торган документлар:

авыл хуҗалыгы терлеген, нәселле продукцияне (материалны) сатып алу (лизингка) шартнамәләренең күчермәләре;

түләү йөкләмәләренең һәм (яки) авыл хуҗалыгы терлеге, нәселле продукция (материал) өчен түләүгә аккредитив ачуны раслый торган документларның кредит оешмасы тарафыннан танылканган күчермәләре;

валюта күчерүне раслау турында свифт хәбәрләрнең күчермәләре;

йөк таможнясы декларациясенең күчермәсе (йөк таможнясы декларациясен законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә рәмиләштергәннән соң тапшырыла);

импорт алыш-бирешенең паспорты күчермәсе;

импорт алыш-биреше паспортының торышы турында белешмә;

сатып алынган нәселле продукциянең (материалның) нәселлек ягыннан кыйммәтен раслый торган документлар.

Агымдагы елда алынган кредитның (заемның) гомуми суммасы бер кооперативка 15 миллион сумнан артык булмаганда, сезонлы эшләр башкару өчен матди ресурсларны, яшь авыл хуҗалыгы терлеген сатып алуга, беренчел һәм сәнәгать шартларында эшкәртү өчен үзебездәге авыл хуҗалыгы чималын (2013 елдан башлап - беренчел һәм сәнәгать шартларында эшкәртү өчен үзебездәге авыл хуҗалыгы чималын), кооператив әгъзалары тарафыннан алга таба сату өчен җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясен сатып алуга, шулай ук кооперативны оештырылу ягыннан төзекләндерүгә һәм авыл хуҗалыгы продукциясен иминләштергәндә иминият кертемнәрен түләүгә;

сезонлы эшләр башкару өчен матди ресурслар, яшь авыл хуҗалыгы терлеген сатып алу шартнамәләренең яки товар-транспорт накладнойларының күчермәләре;

азыкны, ягулык-май материалларын һәм запас частьләрне сатып алганда заемга алучы тарафыннан (оешмалардан, ваклап сату җирләрендә яки индивидуаль эшкуарлардан сатып алганда) түләү йөкләмәләренең яки товар чекларының, касса чекларының яки приход касса ордерларының кредит оешмасы тарафыннан танылканган күчермәләре, шулай ук сатып алынган башка матди ресурслар һәм яшь авыл хуҗалыгы терлеге өчен түләү буенча түләү йөкләмәләренең күчермәләре.

Беренчел һәм сәнәгать шартларында эшкәртү өчен үзебездәге авыл хуҗалыгы чималын (алга таба – чимал), шулай ук кооператив әгъзаларыннан авыл хуҗалыгы продукциясен (алга таба – продукция) сатып алуга:

юридик затлардан һәм индивидуаль эшкуарлардан сатып алганда - чимал, продукция сатып алу шартнамәләренең, сатып алына торган чимал, продукция өчен түләү йөкләмәләренең заем алучы тарафыннан танылканган күчермәләре;

физик затлардан сатып алганда – билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән сатып алу актларының күчермәләрен яки сатып алынган чимал өчен түләүне раслый торган накладнойларның һәм документларның күчермәләре.

Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативын, авыл хуҗалыгы кредит кулланучылар кооперативын да кертеп, оештырылу ягыннан төзекләндерүгә алынган кредитлар (заемнар) буенча:

җиһаз, оргтехника, шул исәптән программалы продуктларны, элемтә

чараларын сатып алу, интернет челтәренә тоташу, офис бүлмәләрен арендалау өчен түләү, коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү шартнамәләренең яки товар-транспорт накладнойларының күчермәләрен, түләү йөкләмәләренең, товар чекларының касса чекларының яки приход касса ордерларының (юридик затлардан, ваклап сату җирләрендә яки индивидуаль эшкуарлардан сатып алганда) кредит оешмалары тарафыннан таныкланган күчермәләре.

Авыл хуҗалыгы продукциясен иминләштерүгә :

иминләштерү шартнамәсенең күчермәсе;

иминият кертемнәрен түләү өчен түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре.

Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан раслана торган исемлек нигезендә авыл җирендә туристлыкны үстерү (авыл туризмы), халык кәсепләрен, авыл җирендә сәүдәне үстерүне дә кертеп, шулай ук халыкка көнкүреш һәм социаль-мәдәни хезмәт күрсәтү, кыргый җиләк-җимешләрне, дару үләннәрен һәм башка ашарга яраклы һәм агач булмаган урман ресурсларын хәзерләү һәм эшкәртү белән бәйле юнәлешләрне үстерүгә алынган кредитлар (заемнар) буенча:

төзелешнең титул исемлеге күчермәсе;

объектны төзүгә, реконструкцияләүгә һәм ремонтлауга җыелма сметаның күчермәсе.

технологик җиһазлар китерүгә, подряд эшләрен, башка эшләрне (проект эшләрен, экспертизаны, техник күзәтчелекне) башкаруга төзелгән шартнамәләрнең, төзелеш-монтаж эшләрен башкару графигы күчермәләре.

Эшләр графигы үтәлеп бару дәрәҗәсенә карап тапшырыла торган документлар:

подряд ысулы белән башкарыла торган эшләр, башка эшләр (проект эшләре, экспертиза, техник күзәтчелек) һәм технологик җиһаз өчен, аванс түләүләрен дә кертеп, төзелеш материаллары һәм эшләрне хуҗалык ысулы белән башкарганда читтәге оешмаларның хезмәт күрсәтүләре өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләренең кредит оешмасы тарафыннан расланган күчермәләре;

башкарылган эшләр актларның күчермәләре;

бинаны (корылманы) файдалануга кабул итеп алу-тапшыру актларының күчермәләре (төзелеш тәмамланганнан соң тапшырыла, бу вакытта заем алучыларга субсидия эш этапларын үтәүгә карап түләнә).

Транспорт чараларын, техниканы һәм җиһазларны чит ил валютасына сатып алуны раслый торган документлар:

сатып алу контрактының күчермәсе;

түләү йөкләмәләренең һәм (яки) түләүгә аккредитив ачуны раслый торган документларның кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре;

валюта күчерүне раслау турында свифт хәбәрләрнең күчермәләре;

йөк таможнясы декларациясенең күчермәсе (йөк таможнясы декларациясен законнарда билгеләнгән тәртиптә контракт нигезендә рәмиләштергәннән соң тапшырыла);

импорт алыш-бирешенең паспорты күчермәсе;

импорт алыш-биреше паспортының торышы турында белешмә;

транспорт чараларын сатып алганда тиешле тәртиптә исәпкә куелу турында тамга сугылган транспорт чаралары паспортларының күчермәләре.

Кирәкле җиһазларны, матди ресурсларны, транспорт чараларын һәм инвентарьне сатып алу өчен алынган кредитлар (заемнар) буенча:

оешмаларда, ваклап сату җирләрендә яки индивидуаль эшкуарлардан сатып алганда төзелгән сату-алу шартнамәләренең яки накладнойларының яки товар чекларының төп нөсхәләре, күчермәләре, шулай ук түләү йөкләмәләренең яки касса чекларының яки билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән приход касса ордерларының кредит оешмасы тарафыннан таныкланган күчермәләре, шулай ук транспорт чараларын сатып алганда тиешле тәртиптә исәпкә куелу турында тамга сугылган транспорт чаралары паспортларының күчермәләре.

Кыргый җиләк-җимешләрне, дару үләннәрен һәм башка ашарга яраклы һәм агач булмаган урман ресурсларын (алга таба – кыргый ресурслар) сатып алу өчен алынган кредитлар (заемнар) буенча:

юридик затлардан һәм индивидуаль эшкуарлардан сатып алганда кыргый ресурсларны сатып алу шартнамәләренең күчермәләре, кыргый ресурслар өчен түләү йөкләмәләренең күчермәләре;

физик затлардан сатып алганда, билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән сатып алу актларының күчермәләре яки сатып алынган кыргый ресурслар өчен түләүне раслый торган накладнойларның һәм документларның күчермәләре.

Искәрмә:

кредитны (заемны) чит ил валютасында алган һәм аннары сумнарда файдаланган очракта, инвестиция кредитының максатчан кулланылышын раслый торган документлар исемлеге сумнарда алынган инвестиция кредитының максатчан кулланылышын раслау өчен билгеләнгән документларның исемлегенә туры килә.

12. Идарәләр:

а) субсидияләр бирү турындагы гаризаларны алар кергән көнне үк журналга теркәп куя, ул номерлана, шнурлана һәм аңа мөһер сугыла;

б) әлеге Тәртипнең 10 – 11 пунктлары нигезендә тапшырылган документларны гаризаны теркәгән көнән соң биш көн эчендә карый;

в) күрсәтелгән документлар нигезендә Министрлык тарафыннан расланган форма буенча Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча субсидияләр бирүгә җыелма исәп-хисап белешмәләрен төзи һәм Министрлыкка тапшыра;

г) заем алучы 2016 елның 1 гыйнварыннан башлап әлеге Тәртипнең 10 – 11 пунктлары нигезендә тапшырылган документларны кредит шартнамәсенең гамәлдә булу срогы беткәннән соң 6 айдан да соңгы калмыйча тапшыра.

Субсидияләр бирүдә түбәндәге очракларда баш тартыла:

тулы булмаган документлар комплекты тапшырылганда;

бюджет йөкләмәләре лимитлары булмаганда.

Субсидияләр бирүдән баш тартуга шикаять Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә агымдагы ел дәвамында бирелә.

13. Субсидияләрне күчерү Министрлыкның Федераль казначылыкның

Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган хосусый счетыннан Идарәләрнең Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекләрендә ачылган хосусый счетларына Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр бирүгә җыелма исәп-хисапка нигезләнеп башкарыла.

14. Идарәләр, әлеге Тәртипнең 10 – 11 пунктларында күрсәтелгән документларга нигезләнеп, субсидияләрне заем алучыларның хосусый һәм исәп-хисап счетларына ике кон эчендә күчерәләр.

15. Чыгымнарның бер олешен каплауга субсидияләр, Россия кредит оешмалары һәм заем алучылар белән килештерелеп, күрсәтелгән оешмада счетлары булган берничә заем алучыга берүк вакытта күчерелергә мөмкин.

Түләү йокләмәсе соңыннан әлеге кредит оешмасы тарафыннан чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләрнең күләмен исәпләүдә чагылган чыгымнарның бер өлешен каплауга субсидияләрне заем алучылар счетларына кертү өчен Россия кредит оешмалары счетына күчерелергә тиешле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен субсидияләрнең гомуми суммасына төзелә.

16. Алынган субсидияләр, субсидияләрнең максатчан билгеләнеше буенча файдаланмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң, Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән башлап алтмыш көн эчендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

17. Хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр федераль бюджет керемнәренә субсидияләр алучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

18. Күрсәтелгән акчаларны федераль бюджетка үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә кире кайтарылырга тиеш.

19. Министрлык һәм (яки) дәүләт (муниципаль) финанс контроле органы субсидияләр бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең заем алучылар тарафыннан үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

20. Министрлыкка Идарәләр тарафыннан һәм авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә, туры килү буенча, аларның вазыйфаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

21. Бюджет акчаларының максатка ярашлы кулланылышын Министрлык тикшереп тора.